Үлгәннәрдән түгел, исәннәрдән куркырга кирәк

Без гадиләштереп морг дип атаган урынны медицина белгечләре патологик анатомия бүлеге дип йөртә. Суд медицинасы бүлекләре фаҗигале рәвештә вафат булган кешеләрне тикшерсә, патологик анатомия бүлегенә күбесенчә авырып бакыйлыкка күчкәннәрне китерәләр. Ничек кенә булмасын, барыбер куркыныч тоела анда.

5 БИТ

ЯНСУАРНЫ без дә яраттык

Узган елда уткәрелгән «Безнең авыл» фотобәйгесе моның шулай икәнен кабат раслады. «Шәһри Казан» вәгъдә иткән җырчылар белән бергәләп, узган ел ук инде җиңүче авылларның кайберләренә барып, чын мәгънәсендә бәйрәм ясап кайтты. Чират әлеге конкурста 142433 тавыш җыеп, икенче урын яулаган Питрәч районы Янсуар авылына да җитте.

7 БИТ

1990 ЕЛДАН БИРЛЕ ЧЫГА

Шәһри КАЗАН

татмедиа

Җомга | 10.02.2017 | № 14 (5776)

www.shahrikazan.com

ТАТАРСТАН БАШКАЛАСЫНЫҢ КӨНДӘЛЕК ИҖТИМАГЫЙ-СӘЯСИ ҺӘМ МӘДӘНИ ГАЗЕТАСЫ

МУЗЕЙ САЕН СУВЕНИР

Татарстандагы һәр музейның үз сувенирлары булачак. Чит илләрдә ул яңалык түгел, анда һәр музейның йөзен чагылдырган үз сувенир линиясе бар. Бу бигрәк тә туристларны җәлеп итү максатыннан отышлы. «Татар-информ»да булган бер матбугат очрашуында Милли музейның генераль директоры Гөлчәчәк Нәҗипова шулай дип белдергән иде.

Дилбәр ГАРИФУЛЛИНА

Илдар Мөхәммәтҗанов фотолары

– Монда, әлбәттә, инвесторларсыз булмый. Әмма бизнес өчен ул – отышлы вариант. Эшмәкәр музейга үз сувенирын тәкъдим итә, музейлар исә аларны сату мәйданчыгы булып торачак, – дигән иде ул.

Әйткән сүз – аткан ук. Эшне озакка сузмыйча, Татарстан Республикасы Милли музее, Татарстанның Мәдәният министрлыгы һәм Татарстан музейлары ассоциациясе «Музей сувенирлары» дигән бәйге дә игълан итте. Оештыручылар сүзләренчә, музейлар саны көннән-көн арта һәм аларның эшчәнлеге республиканың икътисади һәм мәдәни үсеше ягыннан төп ресурс булып тора. Чит илләр һәм Россия музейлары практикасыннан күренгәнчә, музей сувенирлары туризмны да үстерүгә булыша. Бәйгедә музейлар гына түгел, сәнгать белгечләре, һөнәрчеләр, осталар, рәссамнар, дизайнерлар, реклама агентлыклары, сәнгать мәктәбендә укучылар да катнаша ала. Җиңүчеләр ике номинациядә билгеләп үтеләчәк: «Музей сувенирлары» (музейлар өчен) һәм «Музей сувенир продукциясе линейкасы» (дизайн-проект). Җиңүчеләргә акчалата бүләкләр каралган. «Музей сувенир продукциясе линейкасы» номинациясендә иң яхшылары дип табылганнарның сувенирларын җитештерүчеләргә тәкъдим итәчәкләр.

«АЛАБУГА ЧЕБЕНЕ»

Бездә музей сувенирлары бөтенләй юк дип әйтеп булмый. Милли музейда үзләрендә саклана торган балчык чүлмәк күчермәләрен әзерлиләр. Аларны кунаклар үз куллары белән дә ясый ала.

Туристлар арасында иң билгеле сувенир исә «Алабуга чебене» дип аталган рюмка. 2015 елда ул «Туристик сувенир» бөтенроссия фестивалендә «Иң яхшы музей сувенирлары» номинациясендә җиңеп чыкты. Аның оригиналы музейда саклана. Аңардан сувенир ясау идеясе белән музей директоры Гөлзада Руденко чыга. Исеме дә кызык – «Алабуга чебене».

– Аның тарихы Петр I идарә иткән чорларга барып тоташа. Беренче трактирлар барлыкка килгәч, аларның хуҗалары килүчеләргә беренче рюмка аракыны бушка бирергә тиеш була. Чыгымнары күп булмасын өчен, трактирчылар кечкенә булганга «чебен» исеме алган 10-15 мл лы рюмкалар куллана башлый. Аларның берсе музей фондында саклана. Аңа хәтта патент та алдык. «Алабуга чебене» туристлар арасында иң популяр сувенир санала. Сезон вакытында, кайнар пәрәмәчләр кебек, тиз арада сатыла да бетә. Кайбер туристлар музей белән танышканчы, экскурсия башланганчы ук шул рюмканы сорап ала. Алабугага килгәндә, аның турында инде хәбәрдар булалар, – дип сөйләделәр безгә Алабуга дәүләт тарих-архитектура һәм сәнгать музее хезмәткәрләре.

КАЗ КАНАТЫ КАУРЫЙ-КАУРЫЙ, ХАТЛАР ЯЗАРГА ЯРЫЙ

Державин исемендәге Лаеш төбәге музееның да туристлар яратып ала торган үз сувенирлары бар.

– Каз фермасыннан каурыйлар алып, аларга Державинның автографы куелган пичәт белән басабыз һәм стержень кидерәбез. Бәйгедә дә шул каурый белән катнашырбыз дип уйлыйбыз, – ди музей директоры Фәридә Мортазина.

Музейда Лаеш районы сурәтләнгән сувенир бокаллар, магнитлар, кыңгыраулар да сатыла. Фәридә ханым әйтүенчә, сувенирларга, гадәттә, русча һәм татарча язулар гына куела.

→ Ахыры 4нче биттә.

Үсештә

Икътисад һәм сәнәгать министрлыклары ел нәтиҗәләре белән уртаклашты

«КАМАЗ»дан – яңа кабиналар, «акыллы» машиналар, Казан авиация заводыннан – Ту-160 очкычы, Кукмарадан – итекләр, сендвич панельләр... Икътисад министрлыгы белән Сәнәгать һәм сәүдә министрлыгының уртак коллегиясендә Татарстан икътисадының көндәшлеккә сәләтен арттыра торган төп нигез – оешмаларның инновацион үсеше хакында сөйләштеләр.

Эльвира МОЗАФФАР

Коллегияне Татарстан Президенты Рөстәм Миңнеханов алып барды. Чыгышлар башланганчы ук, ул узган ел нәтиҗәләре уңай булуын билгеләп үтте, статистик мәгълүматлар белән таныштырды. Быелтыр республиканың тулаем продукция күләме – 1 триллион 944 миллиард сум, төп капиталга инвестицияләр кертеме 658, 5 миллиард сум тәшкил иткән. Татарстан уңайлы инвестиция мохите булдыру буенча рейтингта инде икенче ел рәттән беренчелекне бирми. Эшмәкәрлекне җәелдерү буенча да алга таба республикада уңайлы шартлар тудырылачагына басым ясады Президент.

«Берләшкән авиатөзелеш корпорациясе» оешмасы президенты Юрий Слюсарь алдагы ун елда аеруча мөһим эшләрнең берсе дип Ту-160 проектын атады. Ту-160 стратегик һөҗүм очкычы Россия армиясендә төп корал булып тора. Проектның 30 елдан артык тарихы бар, инновацион алымнар ярдәмендә ул заманчалаша. Ул цифрлы модельгә күчереләчәк. Самолетны модернизацияләүнең 40 проценты Казан авиация заводы көче белән башкарылачак. Марттан очкыч беренче тестлар узачак, апрельдән югары технологияләр ярдәмендә ТУ-160ның тышкы кыяфәтен яңарту эшенә керешәчәкләр. Рөстәм Миңнеханов, әлеге эшне хуплап:

– Бу – зур, мөһим проект. Без аны гамәлгә ашыруда тулы ярдәм күрсәтәчәкбез, – диде.

Коллегиядә Татарстанның бренды булып саналган «КАМАЗ» ширкәте эшчәнлеге белән дә таныштырдылар. Быелдан оешма авыр йөк машиналарының яңа төрен эшли башлаячак. 2019 елдан автомобильләр өчен 6 цилиндрлы заманча двигательләр, куркынычсыз, чыдам кабиналар эшләү күздә тотыла, шул ук вакытта «КАМАЗ» – пилотсыз транспорт өлкәсендә эш алып баручы да. Кешедән башка эшли торган «акыллы» машиналарны, тәгәрмәчләргә, пилотсыз микроавтобусны тиздән республика юлларында сынап карарга җыеналар.

Районнардагы сәнәгать эшчәнлегенә дә уңай бәя бирелде. Авылда беренче сәнәгать мәйданчыгын булдырган, бүген анда җитештерелгән сендвич панельләре белән бөтен илгә танылган Кукмара районы үрнәк итеп китерелде. Мәскәү кунакларына Президент Кукмараның савыт-саба, итекләре белән дан тотуын да искәртеп узды.

Икътисад министры Артем Здунов чыгышында быелтыр икътисад үсешенә сәнәгать җитештерү, авыл хуҗалыгы һәм төзелеш өлкәсе аеруча зур өлеш керткәнлеген әйтте.

– Быелтыр республикада 2,4 миллион квадрат метр мәйданда торак тапшырылды, аның 367 мең квадрат метры – социаль ипотека программасы буенча салынган йортлар. Төзелеш өлкәсендә 286 миллиард сумлык эш башкарылган, – диде ул чыгышында.

Сәнәгать һәм сәүдә министры Альберт Кәримов исә коллегиядә катнашучыларны маркетинг системасында заманча технологияләрне кулланырга өндәде. Интернетның өстенлекләрен «Татспиртпром» чыгара торган «Ханская» аракысы мисалында да аңлатырга тырышты.

– Барыгыз да ЕГАИС системасы белән таныш. Кыскасы, һәр җитештерүче үз товарына махсус чип урнаштыра. Әлеге чип интернетка тоташтырыла. Нәтиҗәдә, кулланучы продуктны адымлап күзәтә ала. ЕГАИС системасы ярдәмендә продуктның кайчан, кемгә сатылганын белергә мөмкин (бу вакытта слайдта нәкъ менә «Ханская» шешәсе пәйда булды. – **Авт.**). Хәтта менә бу аракыны сатып алучы күпме эчкән, икенче шешәне алырга кайчан киләчәген дә чамаларга була, – дип сөйләде министр.

Аның фикеренчә, мондый технологияләр куллану Татарстан җитештерүчеләре өчен көндәшлеккә сәләтне арттырачак.

«Внешэкономбанк» рәисе урынбасары, «Моношәһәрләр үсеше фонды» коммерциячел булмаган оешманың күзәтчелек советы әгъзасы Ирина Макиева чыгышы вакытында зал аеруча җанланып алды. Әлегә Татарстанда бары бер Чаллы шәһәре генә алга киткән социаль-икътисади үсеш территориясендәге моношәһәр статусына ия. Быел исә бу исемгә Түбән Кама һәм Яшел Үзән шәһәрләре дә дәгъва кыла. Тик Ирина Макиева Рөстәм Миңнехановка бар шәһәрләрне дә программага кертеп карарга кирәк, дип тәкъдим итте. Моношәһәрләрдә заманча медицина, яңа эш урыннары, төзек юллар булачак. Һәр шәһәр ашыгыч ярдәм хезмәте машиналары белән тәэмин ителәчәк. Президент, уенын-чынын бергә кушып:

– Ашыгыч ярдәм машиналары кирәк безгә, искергән 150 машинаны алыштырырга җыенабыз. 100ен үзебез алырбыз, сездән – 50се, – дип тә әйтеп куйды. Бу фикерне зал көчле алкышларга күмде.

– Моношәһәрләр юнәлешендә бүген зур эш башкарыла: бу яңа эш урыннары, заманча мохит. Элек җитештерү, инфраструктура турында гына сөйләсәк, бүген без бу шәһәрләр башкалар кебек үк уңайлы булырга тиеш дип сөйлибез. Кешедә читкә күчеп китәргә теләк туарга тиеш түгел. Алар эш урыннары, хезмәт хакы һәм балаларын яхшы мохиттә тәрбияләр өчен шартлар булуына ышанган булырга тиеш, – диде Президент.

Коллегия азагында хезмәтендә югары уңышка ирешкәннәрне тәбрикләделәр. Татарстан Президенты Рөстәм Миңнеханов та Россия алдындагы уңышлары өчен мактау билгесе белән бүләкләнде.

Alibaba (коммерция өлкәсендә эшләүче танылган Alibaba Кытай компаниясе) бер секунд эчендә 140 мең килешү төзергә өлгерә. Мин сезгә бу сүзләрне сөйләп торганда, алар инде миллионлаган килешү төзегәндер. Безгә дә заманча технологияләрдән күбрәк файдаланырга кирәк. Бу – көндәшлеккә сәләтне арттырачак.

Сәнәгать һәм сәүдә министры Альберт Кәримовның коллегиядәге чыгышыннан.

Сулыклар быел да күзәтү астында

Быел экологлар Татарстандагы су объектларын көчле күзәтү астына алачак. Әйтик, суның сыйфатын алар хәзер ай саен тикшерә.

– 2016 елда без табигатькә кагылышлы 1735 хокук бозу очрагын ачыкладык. Моңа сулыкларны пычрату, елга-күлләргә керү юлларын каплау, сусаклау зоналарында хокук бозу кебек очраклар да керә, – диде Татарстан экология һәм табигый байлыклар министры урынбасары, әйләнә-тирәне саклау буенча баш инспектор Фаяз Шакиров.

Узган ел республикада сулыкларга юл ябуның 432 очрагы теркәлгән. Яр буенда урнашкан 365 корылма инде җимерелгән. Хәзерге вакытта 67 эш – суд карамагында.

– Экология елының төп максаты – әлеге юнәлештә эшне дәвам итү, – диде Фаяз Шакиров.

Тиздән табигатькә зыян салган кешене, үзе булмаса да, административ җаваплылыкка тартып булачак. Хәзерге вакытта закон проекты Россия Дәүләт Думасы тарафыннан карала. Бу законны гамәлгә кертү өчен, 2016 ел ахырында министрлык махсус программалы 55 планшет сатып алды. Аның ярдәмендә инспекторлар урында ук хокук бозуны теркәп, протокол тутыра ала.

– Хокук бозучылар җаваплылыктан китәргә тырышкан очраклар күп. Хәзерге вакытта табигатькә зыян салуны фото һәм видео аша теркибез. Проект уңышлы гына эшләп китсә, министрлыкның бөтен инспекторларына мондый планшет таратылачак. Бу, лаборатория хезмәткәрләре белән бергә, 250 кеше диган сүз, – диде Фаяз Шакиров.

Шулай ук законсыз рәвештә карьер казыган кешеләр документларын күрсәтүдән баш тартырга мөмкин.

– Полиция хезмәткәрләреннән башка кайбер хокук бозучылар исем-фамилияләрен, кайда эшләүләрен әйтергә теләми. Без карьерны, хокук бозучының техника номерларын фотога төшерсәк, ЮХИДИ хезмәткәрләре ярдәмендә аларны административ штрафка тарта алыр идек. Мондый планшет тизрәк һәм нәтиҗәлерәк эшләргә ярдәм итә, – диде дәүләт инспекторы.

Алисә САБИРОВА.

ОДН: урыны үзгәрә, түләү кала

Күпкатлы йортларда яшәүчеләргә, кулларына карандаш белән дәфтәр алып, янә математиканы эшкә җигәргә туры киләчәк. Чөнки ел башыннан Россия Торак кодексындагы яңа нормативлар гамәлгә керде.

Дамир БӘДРИЕВ

images.aif.ru

Күпкатлы йортта гомумйорт ихтыяҗларына (ОДН) тотылган салкын су, җылы су, электр энергиясе, шулай ук подвалга җир астыннан саркып чыккан суларны корыту эшләре өчен түләү алына. Күпкатлы йортта яшәүчеләр моңа кадәр гомумйорт ихтыяҗлары, ягъни чыгымнары өчен түләүләрне хисап кәгазендә «коммуналь хезмәтләр» графасында башкардылар. Хәзер әлеге түләүләр «торакны карау» (содержание жилого помещения) графасына күчерелде.

– Гомумйорт чыгымнары өчен түләү бәяләре республиканың Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык министрлыгы белән Тарифлар буенча дәүләт комитеты билгеләгән нормалардан артып китәргә тиеш түгел, – дип искәртте республиканың төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык министрының беренче урынбасары Алексей Фролов.

Татарстанның дәүләт торак инспекциясе җитәкчесе Сергей Крайнов әйткәнчә, хисап фактурасында графа үзгәрсә дә, түләү үзгәрмәячәк.

– Без әлегә 2016 елда кабул ителгән тарифлар нигезендә түлибез. Яңа тарифлар әле быелның 1 июлендә генә кабул ителәчәк, – диде ул. – Гомумйорт ихтыяҗларына тотылган энергия чыганаклары нормалардан узса, артып киткән өлеш күпкатлы йортта яшәүчеләргә бүленергә тиеш түгел.

– Күпкатлы йортта подъезд идәннәрен, тәрәзәләрен юуга су нормалары билгеләнә. Җәйге айларда агачларга һәм чирәмлеккә сибелгән су да шушы нормаларда исәпкә алынган, – диде Алексей Фролов.

Җыеп кына әйткәндә, коммуналь түләүләр, шул исәптән гомумйорт ихтыяҗлары өчен түләүләр быелның 1 июлена республиканың Тарифлар буенча дәүләт комитеты тарафыннан яңа тарифлар кабул ителгәнчегә кадәр үзгәрешсез кала. Ләкин ОДН мәсьәләсе чишелде, дип тынычланырга иртә әле.

– Казанда күпкатлы йортлар хисаплагыч приборлар белән җиһазландырылган. Әгәр күпкатлы йортта гомумйорт ихтыяҗларын хисаплаучы прибор булмаса, анда яшәүчеләр гомуми чыгымнарның нормативлар буенча түләячәкләр. Кайбер фатирларда бер кеше күрсәтелсә дә, унлап гастарбайтер яши. Шуннан күпме ОДН җыела. Торак милекчеләре мондый тискәре мисалларны вакытында хәбәр итсеннәр иде, – диде шәһәр Башкарма комитетының торак-коммуналь хуҗалык комитеты рәисе Искәндәр Гыйниятуллин.

– Торакка хезмәт күрсәтүче оешмалар вәкилләре өч айга бер мәртәбә фатирларга кереп, хисаплагыч приборларны тикшерергә хокуклы. Хисаплагыч приборларның күрсәткечләрен механик юл белән үзгәрткән кешеләргә зур күләмдә штраф салына, – дип кисәтте Сергей Крайнов.

Алексей Фролов та торак милекчеләрен күпкатлы йортларның беренче катларына яки подвалларына урнашкан кафе, чәчтарашханә кебек кече предприятиеләрне контрольдә тотарга чакырды.

– Күпкатлы йортта ОДН түләүләре бурычлары тупланса да, идарәче компанияләрнең әлеге йортка хезмәт күрсәтүне киметергә яки туктатырга хокуклары юк, – диде ул.

КЕШЕ ҺӘМ ХОКУК

Сөртергә дигәнне эчәргә ярамый

Татарстан Республикасы дәүләт алкоголь инспекциясе быел сәүдә маркасы булмаган спирт катнашмалы сыекчаларны яшертен рәвештә сатуның 12 очрагын ачыклаган инде.

Дамир Бәдриев фотосы

– Юридик затлар, ягъни кибетләр алкоголь продукциясен лицензия нигезендә сата. Алар маркасы, ягъни сәүдә тамгасы булмаган спиртлы эчемлекләрне кабул итми. Маркасыз спиртлы эчемлекләрне, гадәттә, аерым кешеләр сата. Мондый очраклар төнге клубларда һәм кальян кафеларында да күзәтелә. Биш литрлы савытлардагы этил спирты катнашмалы сыекчага метил спирты да кушылганлыгын иснәп кенә белеп булмый. Җитештерүчесе һәм товар документлары булмаган спиртлы эчемлекне гомумән эчмәскә кирәк, – дип кисәтә Татарстан Республикасы дәүләт алкоголь инспекциясенең контроль-инспекция бүлеге җитәкчесе Татьяна Хәбибуллина.

Россия Федерациясенең баш санитар табибы карары нигезендә, 28 процент һәм аннан да күбрәк өлешен спирт тәшкил иткән гигиена продукциясен сату быелның 27 мартына кадәр чикләнде. Бу исемлеккә «Боярышник», «Тоник», «Лосьон» һәм гигиена максатларындагы товарлар керә. Автомобиль тәрәзәләрен юдыргыч сыекчаларга бу чикләү кагылмый.

– Сөртергә дип язылган икән, димәк, аны һич кенә дә эчәргә ярамый. Укырга кирәк бераз. Кеше гомере 35 сумлык «фанфурик» бәясендә түгел ләбаса. Гаиләгә күпме хәсрәт. Иркутск шәһәрендә әнә берьюлы ничә кеше үлде, – диде Татьяна Хәбибуллина.

Сәүдә маркасы булмаган спиртлы эчемлекләр сатканы өчен гадәти гражданнарга – 4-5 мең сум, эшкуарларга 10-15 мең сум штраф салына.

Ялган спиртлы эчемлекләр сатучыларны фаш итүчеләргә акчалата премия бирелә. Татарстан Республикасы дәүләт алкоголь инспекциясенең «кайнар элемтә» телефоны – **(843) 278-92-79.**

Рәдиф КАРАГАЙ.

Газетабызның алдагы санында «Татфондбанк» белән бәйле хәлләрдә беренче гаепләнүчеләр ачыклануы турында хәбәр иткән идек.

Тагын бер карак табылды

«Татфондбанк»тан әлеге банкның бүлендеге булган «ТФБ Финанс» инвестиция компаниясенә кертемнәр күчергәндә акча урлауда шикләнелгән кешеләр тоткарланды. «ТФБ Финанс» инвестиция компаниясе директорын Совет район суды 1 ай да 27 көнгә кулга алды. «Аерата зур күләмдә урлау» маддәсе буенча кулга алынган җинаять эшендә «ТФБ Финанс» инвестиция компаниясенең актив операцияләр идарәсе башлыгы һәм компаниянең клиент сервисы бүлеге җитәкчесе дә гаепләнә. Тикшерү эшләре барышында тагын бер урлаучы ачыкланды. ПАО «Татфондбанк» идарәсе рәисе урынбасары Вадим Мерзляков кулга алынды, дип хәбәр итә Татарстан Эчке эшләр министрлыгының матбугат хезмәте. Кертемчеләргә барлыгы 90 миллион сумнан артык зыян салынган, дип фаразлана. Тикшерү эшләре дәвам итә.

Ташландык баланы гаиләгә алачаклар

27 гыйнварда Чаллы бәби-боксында калдырылган баланы 40лап гаилә тәрбиягә алырга тели, дип яза «Новая Кама» газетасы.

Чаллы шәһәре башкарма комитетының Опека һәм попечительлек бүлеге җитәкчесе Роза Гернер сүзләренчә, баланы гаиләгә биргәнче, булачак әти-әниләр махсус курс үтәргә тиеш. Шундый 15 курс үткәнлеккә таныклык алган да инде. Хәзерге вакытта бәби-бокста калдырылган баланың беренче документларын әзерлиләр. Аңа Маша дип исем кушканнар. Сабый әлегә Кама балалар медицина үзәгенең яңа туган балалар бүлегендә. Аннары аны балалар йортына күчерәчәкләр. Ярты ел эчендә баланың әнисе килеп, аны кире алырга теләк белдерүе дә мөмкин.

Искәртеп үтәбез, сабыйны Кама балалар медицина үзәге бәби-боксына калдырып киткәннәр иде. Сабый янында аның бала тудыру йортында тууы һәм тиешле барлык прививкалар ясалуы турында язу да булган. 2015 елның маенда бәби-бокс ачылганнан бирле бу – бала калдыруның беренче очрагы.

Сагыныр кешең булу үзе бәхет

Арча районы, Урта Пошалым авылының иң өлкән кешесе Гөлҗәүһәр апа Борһанова быел 90 яшьлек гомер бәйрәмен каршыларга җыена. Шушы күркәм яшендә дә Коръәнне гарәпчә укып, «Ак Барс» хоккей командасына теләкләр тели-тели, догалар укый-укый чын күңелдән җан атып утырган әбекәй озын гомерле булуының серен сабырлыкта һәм сәяхәт итүдә, ди.

Илдар Мөхәммәтҗанов фотосы

Зәһрә САДЫЙКОВА,
Арча, Урта Пошалым

– Мин бик сабыр булдым. Кешеләр белән бәхәсләшеп, алар белән сүзгә килергә бер дә яратмадым. Юлымда гел әйбәт кешеләр генә очрады. Укучыларым да, хезмәттәшләрем дә бик яхшы булдылар. Озак еллар узса да, хәл белешеп, хәбәрләшеп торабыз, – ди Гөлҗәүһәр апа.

Ул гаиләдә төпчек бала булып туган. Җидееллык мәктәпне тәмамлаганнан соң, 1942 елда педагогика училищесына укырга кергән.

– Сугыш еллары иде бит – уку дәвере кыска булды. Ул вакытларда колхозда төрле эшләрдә эшләдек, I курстан соң урман ташырга җибәрделәр. 1945 елны башлангыч сыйныфларны укыта башладым. Аннан соң Түбән Пошалымда эшләдем, институтның татар теле һәм әдәбияты бүлеген тәмамлаганнан соң, 1950 елдан башлап пенсиягә чыкканчы, татар теле һәм әдәбиятын укыттым. Шул чорларда газеталарда кыска гына язмаларым да басылды. Элек бит укучылар күп иде, шунлыктан өч сменада эшләдек. Укыту белән хезмәт бергә алып барылды. Гаиләбездә ир баладан абый гына иде. Ул да сугышта үлеп калды. Әти-әнине тәрбияләү безнең өстә булды. 70нче елда училищега эшкә чакырганнар иде дә, өлкән яшьтәге әти-әнине калдырып китәсем килмәде, – ди ул.

Гөлҗәүһәр апаның балалары булмаган. Чәчләре чәчкә бәйләнгән кешесе белән дә тормышлары барып чыкмаган – юллары тиз аерылган. Бүгенге көндә ул апасының кызы Нурзада Шәфиева гаиләсендә яши.

– Туганнарым, аларның балалары күп булгач, үземне якын итеп торгач, ялгызлыкны да сизмәдем мин. Бик яхшы тәрбияләүләр, Аллага шөкер, – ди ул.

Хәер, Гөлҗәүһәр апа үзе дә сөбханалла әле. Озак еллар авылда абыстай вазифасын башкарган. Егермедән артык мәетне юып, соңгы юлга озатырга туры килгән аңа. Бүген дә күзләре күрә, намазларын-догаларын калдырмый, үзләреннән гарәпчәне өйрәнеп, Коръән укый.

– Аллага шөкер, тормышымнан канәгатьмен, пенсияне дә яхшы түлиләр. Авылда ашта булмаган кешем юк. Күрше авылларда да күп кунак булдым. Әти-әнием дә бик гыйлемле, укымышлы кешеләр иде. Кызганыч, ул елларда дин турында гына сөйләргә ярамады. Әтием Борһан, бик үгетләгәч, танышының улына никах укыды. Килен кеше шул никах укытылу турында райкомга барып әйткән. Мине чакыртып: «Әтиеңә әйт, дин тыела», – дип кайтардылар. Әти әни үлгәннән соң 16 ел яшәп, 88 яшендә дөнья куйды, – дип искә ала әбекәй.

– Безнең апабыз – заманча әби ул. Дөнья хәлләреннән дә хәбәрдар. Бик күп сәяхәт иткән кеше. Аның озын гомерле булуының сере дә әнә шуңа бәйледер, дип уйлыйм, – дип сүзгә кушылды Нурзада апа.

– Әйе шул, балаларым булмагач, бик күп шәһәрләр буенча сәяхәт иттем бит мин, – дип елмая Гөлҗәүһәр апа. – Ике тапкыр Новосибирскида булдым. Анда театрларга барып, Себер татарларының тормышы белән таныштым. Аннан соң РОНОда географ булып Мансур Мусин дигән кеше эшли иде. Ул безне туристик походларга йөртте. Ул елларда Свердловск, Миасс, Златоуст, Ташкент һәм башка шәһәрләргә бардык. Мондый мөмкинлекләр булу – бик зур бәхет бит ул. Дөнья күреп, кешеләр белән аралашып йөрүемә шатланып туя алмыйм, менә хәзер дә бик барыр идем, булмый гына…

Шулай да озын тормыш юлында зур югалтуы булган аның. Гөлҗәүһәр апа сөйләвенчә, ул озак вакыт Әдһәм исемле егет белән аралашып йөргән. Киләчәктә тормыш корабыз, дигән планнары да булган. Әмма кыз институтны тәмамлап, кулына диплом алган елның көзендә егет машинадан егылып һәлак булган.

– Аны уйламаган, догадан калдырмаган көнем юк. Бик сагынам үзен. Бергә булмасак та, тормышымда шундый бик әйбәт кешене очратуым белән дә бәхетле әле мин. Сагыныр кешең булу да бәхет ул. Кияүгә чыккан кешем дә Әдһәм исемле иде. Җан атып йөргән кешемнең исеме җирдә ятмас, дип барган идем… Әмма аның белән озак яшәмәдек. Тормыш йомгагым менә шулай үз җаена акрын гына тәгәри бирә, – дип озатып калды безне гомере буена күңелендә мәхәббәтен сүндерми саклаган Гөлҗәүһәр апа.

Музей саен сувенир

→ Ахыры. Башы 1нче биттә.

–Чит ил туристлары өчен инглиз һәм кытай телендә язылганнарын да чыгарырга кирәк. Сувенирны өенә алып кайта да куя, еллар үткәч, аның кайдан алып кайтканын да оныта. Ә сувенир бит ул – сәяхәтнең бер истәлеге. Узган ел бездә 4600 турист булды. Австралия, Зеландия, Италия, Франция, Германиядән килгән туристлар да бар иде. Кунаклар өчен «Алексеевск нәфис эшләнмәләр туку фабрикасы»ннан җитен тастымаллар алып кайтып, инглизчә Лаеш дип яздырабыз. Аларын да туристлар бик яратып ала. Магнит, ручка, бокаллар алар бөтен җирдә дә бар. Үзенчәлекле, кызыгып алырлык сувенирлар эшләргә өйрәнәсе бар әле безгә, – ди ул.

Кама арты һәм Нурлат шәһәре төбәк музее да бәйгедән читтә калмаска булган. Музей директоры Флюра Мурзаханова сүзләренчә, сувенир Нурлат символы булган «нурлы ат» белән бәйле булачак. Нурлат шәһәренең үзәк мәйданын да «Нурлы ат» монументы бизәп тора.

– Ат ни рәвешле, нинди материалдан булыр, әлегә уйлыйсы бар. Бераз гына юмор белән дә ясарга кирәк дигән фикер бар. Район күләмендә үзебез дә конкурс игълан итәргә булдык. Бәлки, райондашларыбыз да, кызыклы идеяләр тәкъдим итәр, – ди ул.

Апас туган якны өйрәнү музее директоры Рәмис Ногманов, һәр музейның үз сувенирлары булырга, әмма ул мәктәп укучылары ясаган, чиккән, бәйләнгән әйберләрдән торырга тиеш түгел, дигән фикердә тора.

– Яңа ел алдыннан «Музей базары» ярминкәсе оештырылган иде. Андагы күзәтүләремнән чыгып әйткәндә, музейның үзендә эшләнгән үз йөзе булырдай сувенирлар аз. Безнең башкаларны кабатламый торган, юкәдән ясалган ручкаларыбыз бар. Аларны мин үзем эшлим, чималын яздан әзерләп куям. Заманнан артта калып булмый, соңгы елларда эчке туризмны үстерүгә зур игътибар бирелә. Әлеге эштә музейларның да өлеше зур. Туристлар хәзер башкалабыз белән генә түгел, республика районнары белән дә теләп таныша, – ди ул.

Җиңүчеләр хаҗга барачак

2003-16 елларда Азнакайда Россиянең спорт мастеры Әсләм Шакиров истәлегенә татар-башкорт көрәше буенча республика ачык турниры оештырылып килде. 14 тапкыр узды ул.

Быел исә Әсләм Шакировның уллары эшмәкәр әтиләре исеме белән бәйләп, республика күләмендә узачак бөтенләй үзгә бәйгегә баш саптылар. Шунда ук әҗерен дә әйттеләр: I-II урынга Шакировлар гаиләсе исеменнән олы хаҗга һәм гомрә хаҗына ике юллама тапшырылачак.

– Без идея бирүчеләр генә. Бу эш өчен башыннан ахырына кадәр җан атып йөрүчеләргә, бигрәк тә Азнакай район хакимияте, Азнакай районы мөхтәсибәтенә, көньяк-көнчыгыш төбәге казыятенә, Татарстан Мөселманнары диния нәзарәтенә бик рәхмәтлебез. Бәйге бик югары дәрәҗәдә узды. Безнең төбәктә мондый чараның моңа кадәр булганы юк иде әле, – ди Әсләм Шакировның эшен дәвам итүче олы улы Руслан әфәнде.

«Әсләм» дип аталган әлеге бәйгенең шарты буенча, анда катнашучылар Коръәннең соңгы өч өлешен 28,29,30нчы җөзләрен яттан сөйләргә тиеш иде. Тагын шунысы – конкурсантларның барысының да татар телен белүе һәм республика мөхтәсибәтләрендә яшәүләре шарт. Таләпләр чыннан да бик югары, жюри да үтә дә саллы: катнашучыларга бәяне Корьән-хафизлар, Татарстан Диния нәзарәтенең Коръәнне өйрәнү бүлеге вәкилләре Булат хәзрәт Мөбарәков, Идрис хәзрәт Кыямов, Илнур хәзрәт Хәйруллиннар бирде.

Мөхтәрәм кунаклар арасында Татарстанның баш казые Җәлил хәзрәт Фазлыевның, Татарстан мөфтие урынбасары Рөстәм хәзрәт Хәйруллинның булуы шулай ук чараның дәрәҗәсен билгеләүче фал иде.

Район һәм шәһәр мәдәният йортында узган бәйгедә катнашучылар гына түгел, аны тамаша кылырга килүче һәркем көтеп алынган кунак булды ул көнне. Шуңа да бәйге көне буе барса да, аны калдырып кайтып китәргә ашыгучы булмады. Күрше залда мул итеп әзерләнгән табын барысын да сыйдырды.

Бер яхшылык икенчесен тартып китерә дигән сүз дә бу очракта рас килә иде. Ни өчен дигәндә, җиңүчегә тәгаенләнгән ике олы бүләк өстенә хаҗга тагын ике юллама бүләк итүче табылды. Бу икәүнең үзләренең кем булуын белгертәсе килмәсә дә, барысы да рәхмәтле иде аларга да: үз игелекләре үзләренә кайтсын, Ходай кабул итсен...

Шулай итеп, республика бәйгесендә беренчелекне алган Нияз Минсабиров (Әлмәт), Эрнест Нәфыйков (Түбән Кама), Рамазан Идрисовлар (Зәй) олы хаҗга юлламалы булды. Икенче урынны яулаган Мөхәммәтгали Корбановка исә (Әгерҗе) гомрә хаҗына юллама тапшырылды. Бәйгедә катнашкан Инсаф Вәлиев (Казан) Азнакай районы башлыгы Марсель Шәйдуллинның махсус бүләге – ноутбукка ия булды.

– Бик риза калдык бу бәйгедән. Җәлил хәзрәт Фазлыевның вәгазьләрен дә тыңлап туймаслык булды. Күрегез инде, 9-12 яшьлек балаларга кадәр катнашты бит. Ничек инде шуңа күңел булмасын. Күңелләр тулып елый-елый тыңлап утырдым. Килеп-килеп, кочаклый-кочаклый, рәхмәтләрен дә әйттеләр. Бу бәйге дәвамлы булыр, иншаллаһ, – ди Әсләм Шакировның хатыны Мәдинә абыстай да.

Мәдинә абыстай үзе дә менә инде өченче ел туган авылы Әсәйдә һәм күршедәге Митрәйдә дин дәресләре алып бара. Уллары-киленнәре дә барысы да исламда аның.

Расиха ФӘИЗОВА.

Үлгәннәрдән түгел, исәннәрдән куркырга кирәк

Без гадиләштереп морг дип атаган урынны медицина белгечләре патологик анатомия бүлеге дип йөртә. Суд медицинасы бүлекләре фаҗигале рәвештә вафат булган кешеләрне тикшерсә, патологик анатомия бүлегенә күбесенчә авырып бакыйлыкка күчкәннәрне китерәләр. Ничек кенә булмасын, барыбер куркыныч тоела анда. Баксаң, табиблар үзләре үк бу урынны шомлы дип саный һәм күбесе биредә эшләүчеләрнең нәрсә белән шөгыльләнгәнен тулысынча белеп тә, аңлап та бетерми икән. Без Медицина клиник диагностика үзәгендә (МКДҮ) патологоанатом булып эшләүче, 40 елдан артык эш тәҗрибәсе булган медицина фәннәре кандидаты **Васыл АБДУЛЬЯНОВ** белән сөйләштек.

СОҢГЫ ТАБИБ

Татарстанда уннан артык патологик анатомия бүлеге исәпләнә. Ул һәр зур хастаханәнең үзендә бар.

– Республика клиник онкология диспансерының мондый бүлеге, мәсәлән, республикада алдынгылар рәтендә. Хастаханәнең элеккеге баш табибы, хәзер Казан дәүләт медицина академиясе ректоры Рөстәм Хәсәнов (минем студентым) бу бүлекне торгызу өчен күп өлеш кертте, – ди Васыл әфәнде. – Чит илләрдә патологик анатомия бүлекләрендә кыйммәтле микроскоплар, махсус көйләнгән, бер төймәгә басып кына төшерә торган фотоаппаратлы өстәлләр кулланыла. Бездә дә бу өлкәдә заманча технологияләргә күбрәк игътибар бирелсен иде.

Патологоанатомны кешенең соңгы табибы дияргә дә була. Ахыргы диагнозны ул куя. Еш кына бу һөнәр ияләре башка табиблар: хирурглар, онкологлар җибәргән биопсия материаллары ярдәмендә авыруга исән чагында ук патогистологик диагностика уздыра. Гади итеп әйткәндә, табиблар авыруга якынча куйган диагнозның төгәллеген алар тикшерә. Шуңа да монда күп белү, тәҗрибәле булу кирәк, ялгышырга ярамый. Васыл Абдульянов: «Яхшы патологоанатом булу өчен кимендә 15 ел эш тәҗрибәсе кирәк», – дип саный. Ул үзе кайбер кешеләрнең үлү сәбәбен, аны ярганчы ук, әчке сиземләү белән тоя икән.

МӘЕТЛӘРГӘ АРТЫК САЛКЫН ЯРАМЫЙ

– Бүлектә эш ничек оештырылган? Соңгы юлга китүчеләрнең барысы да әлеге бүлек аша узамы?

– Әйе. Кеше үлеменең сәбәбе төгәл ачыклансын өчен кирәк бу. Гадәттә, совет чорында өлкән яшьтә авырып үлүчеләрне ярдырырга алып килмиләр иде. Әмма хәзер еш кына, акчасына, мирасына кызыгып, өлкән яшьтәгеләрне үтерү очраклары, фаҗигале хәлләр ешайды. Шуңа да патологик анатомия бүлегендәге тикшерүләр күп сорауларга җавап табарга ярдәм итә. Мәетне ярып тикшергәч, туганнары алып киткәннән соң да, кәгазь эше айдан артыкка сузыла. Кирәк булганда, тән тукымалары анализга алына, тикшерелә, диагнозны махсус комиссия карый. Кешенең үлеме турындагы махсус кәгазьләр гомерлеккә архивта саклана.

– Мәетне килеп алучысы булмаса?

– Татарлар бик тиз алып китә. МКДҮнең патологик анатомия бүлегендә килеп алмаган очракның булганы юк. Әгәр килеп алмыйлар икән, без аны дәүләт хисабына җирләргә тиеш.

– Биредә эшләргә курыкмыйсызмы?

– Үлгәннәрдән түгел, исәннәрдән куркырга кирәк. Мәет белән бергә аның бөтен авырулары да үлә. Дөрес, туберкулез, В гепатиты, себер түләмәсе кебек йогышлы инфекцияләр кеше үлгәннән соң да сакланырга сәләтле.

– Бәлзәмләү ни өчен кирәк?

– Бу – мәет озаграк саклансын өчен кирәк. Җирләү өчен ерак юлга алып чыкканда, җәсаде бозылмасын өчен, бәлзәмләү кулланыла.

– Мәетне саклау мәсьәләсенә дә тукталыйк.

– Ярганчы, махсус суыткычта саклыйбыз. Безнең МКДҮдә өч урынга исәпләнгән суыткычлар бар. Анда дүрт градус җылы. Артык салкын ярамый. Тәндә боз кристаллары барлыкка килсә, тикшерүләр уздыру авырлаша.

– Юу, кәфенләү кебек хезмәтләр дә бармы?

– Бар. Бу өстәмә хезмәтләр түләүле. Без бүлек башкарырга тиеш стандарт эшләрне генә эшлибез.

Сүз уңаеннан, Васыл Абдульянов мәнә инде 40 ел Казан дәүләт медицина университетында патологик анатомия фәнен укыта. Үзе дә бу өлкәгә кагылышлы һәр яңалыкны укып бара. Шәхси китапханәсендә 1901 елгы басмалар да саклана. Төрле яклап эрудицияле булырга кирәк, дип саный ул. Казан дәүләт университетында (хәзер Казан федераль университеты) юридик белем ала, Казан техник илкүләм тикшеренү университетында (КАИ) программалау курсларын үзләштерә.

Морглар турында халык телендә йөргән өч имеш-мимешкә **Васыл АБДУЛЬЯНОВ** аңлатмалары

– Патологик анатомия бүлегендә эшләүчеләр, мәетләрдән курыкмасын өчен, спиртлы эчемлекләр кулланалар, диләр.

– Юк. Бу эштә спиртлы эчемлекләр куллану катгый тыела. Моның өчен эштән куарга да мөмкиннәр.

– Ярырга дип китерелгән мәетләрнең терелү очраклары бар дип ишеткән бар.

– Әкият. Бер суд медицинасы бүлегендә шундый очрак булган. Аңсыз бер исерекне полиция хезмәткәрләре үлгән дип алып килгәннәр. Аны мәет дип суыткычка урнаштырганнар. Аннан чыгарып вакыт җиткәч, исерек суыктан айныган. Селкенгән. Торып ук баскан. Шул чак моргта эшләүче санитар «тере мәет» күреп нык курыккан дип сөйлиләр иде. Башка мондый «үлеп терелү» турында ишеткәнем юк.

– Хәзер кеше күбесенчә экологик яктан чиста булмаган ризыклар белән туклана. Организмында төрле химик матдәләр булган кеше үлгәч тә тиз генә бозылмый, имеш.

– Килешмим. Мәет өч көннән соң бозыла, исләнә башлый. Мөселманнарда өчесен, җидесен уздыру юкка гына килеп чыкмагандыр. Өч көннән соң алынган анализ ярдәмендә төгәл диагноз кую мөмкин түгел.

Патологик анатомия бүлегендә эшләүче лаборантларның уртача хезмәт хакы сигез мең сум тирәсе. Зыянлы эш өчен өстәмә түләү бернәчә ел элек бетерелгән. Күрәсең, медицинадан шактый ерак торган кешеләр өчен бөтенләй аңлашылмаган бу өлкәдә чын-чынлап кызыксынучылар, әлеге эшне үз итүчеләр генә эшли алалар.

Эльвира МОЗАФФАР.

Ядкарь

Туган җирем Әлки районының Төгәлбай авылына XVI-XVII гасырларда ук нигез салынган дип сөйлиләр борынгылар. Элек анда 300дән артык йорт булган. 2000нән артык кеше яшәгән. Су тегермәне, өч мәчете булган бу зур авыл бүген инде кечерәеп калды. Аның каравы, өч зират бар. Хәзер авылда нибары 150 кеше исәпләнә. Колхоз да, совхоз да юк авылда. Эшсезлек.

Авылга кайткан саен, урамнарны урап чыгам. Төгәлбай Иделгә коя торган 50 чакрымга сузылган Бизнә елгасының ике ярында урнашкан. Авылның түбән очында – дүрт урам, тау башы ягында тагын бер урам. Җиде йорт саен 50 метр киңлектә тыкрык бар. Бу ут-күздән саклану өчен шулай эшләнгән. Авылдашларымны барлыйм. Оста һөнәрчеләр Гаҗилә, Нәбирә, Мөгаллләм, Габдрахман бабай... Аларның аяк белән эшли торган «Зингер» машиналары бар иде. Халыкны кием-салым белән алар тәэмин итеп торды. Тун, бишмәт, тула оеклар дисеңме... Гәрәй, Шәяхмәт бабайлар, мич чыгару осталары булып, тарихка кереп калганнар. Ә мәнә күрше Рәҗәп авылы чабатачылары белән дан тотты. Шуңа да Рәҗәп чабаталарын һәр якшәмбе Матакта уза торган базардан алып кайта иде авылдашларым. 1950 елларга кадәр киде халык шул чабаталарны.

Елга авыл буйлап бер чакрымга сузылган. Бер ярдан икенчесенә чыгу өчен бары бер генә күпер бар. Авылда «патша күпере» дип йөртелгән әлеге күперне рус-төрек сугышында катнашкан авылдашларыбыз Вәлиәхмәт белән Җиһанша бабайлар Александр патша әмере белән төзегән, диләр. Патша аларны сугыштагы батырлыклары өчен Георгий ордены белән дә бүләкләргә булган. Җиһанша бабай – минем әни Тәҗелнисаның әтисе. Шул Георгий орденын мин дә хәтерлим. Ул сандык төбендә озак сакланды. Кешегә дә күрсәтми иде аны әни. Тик хәзер мәнә каядыр юкка чыккан.

Без балачакта үк мәчетнең берсен – мәктәп, берсен клуб итеп үзгәрткәннәр иде. Ни хикмәт, берсенең манарасы киселми калды. 1961 елда җәй көне көчле давыл вакытында манара үзеннән-үзе авып төште. Аның биеклеге 40 метр иде. Баскычлар куеп, шунда менеп уйнаганыбызны да хәтерлим. Ауган манараның аен шул тирәдә яшәүче Закир абый алып куйган. 2000 елда шул айны яңа мәчет манарасына куйдылар. Ул ай әле дә үткәннәрнең истәлеге булып тора.

Сөләйман ШАКИРОВ,
Казан.

gossov.tatarstan.ru

Моңлы «Мирас»

Безнең эрага кадәр 384 елда туган борынгы грек фәлсәфәчесе, галим, энциклопедист, кеше җаны турында бик күп трактатлар язган Аристотель Стагирский: «Дуслыкның төп билгесе – аралашудан ләззәт алу», – дигән. Күпме гомерләр үткән, әмма бу сүзләр үз кыйммәтен, үз көчен бүген дә җуймаган.

Габдулла Тукай исемендәге Татарстан дәүләт филармониясе концертлар залында булган «Мирас» ансамбле концерт-тамашасы Аристотельнең хаклыгын үз мисалында раслады. Тамаша татарын, урысын, удмуртын, чуашын, әрмәнен, үзбәген бер залга җыйган иде. Сәхнәдә чын зур сәнгать әсәрләре төрле милләт бизәкләре белән нәкышләнеп, тәсбих төймәләредәй тезелеп барды. «Мирас» ансамбленең ун ел сәхнә тотуына, иҗатта яшәвенә һәм алар шул гомердә нәрсәләргә ирешә алуларына багышланган кичә иде ул.

Әлеге иҗади төркем, Нәҗиб Җиһанов исемендәге Казан дәүләт консерваториясе ректоры Рубин Абдуллинның изге нияте, теләге белән, 2007 елда үзенең эшчәнлеген башлаган. Төркемдәге музыкантларның һәммәсе дә консерватория классларында югары музыкаль белем алган кешеләр. Рөстәм Рәхмәтуллин – «Мирас»ның сәнгать җитәкчесе, баян, милли гармун, тальяннарда уйнаучы, консерватория доценты һәм әлеге уку йорты каршында оешкан милли уен кораллары оркестры дирижеры да. Чәч бөртегенә кадәр һәр күзәнәге музыкадан торган милли җанлы, әдәпле-ипле холыклы бу егет – республиканың, татарның милли байлыгы. Рөстәм дөньяның кайсы гына почмагында чыгыш ясамаган да, татар сәнгате данын изге орлык итеп кайларда гына чәчмәгән! Әлбәттә, дистә еллар буе йөзәрләгән чыгышлар «Мирас» ансамбле белән берлектә. Әлеге төркемдә биш төрле музыка уен коралы яши. Флейта – безнең милли аһәңнәргә, авазларга, татар моңына көч-куәт өстәп торган бик йомшак тембрлы, кеше тавышына якын музыка коралы. Ул – тирән сулыш, осталык, сәламәтлек сорый торган корал. Гөлнара Ярмиева кулында флейта кош баласыдай сөйләшеп җырлый ала. Тәҗрибәле, хисле, профессиональ музыкант. Кимәнәдә (скрипка) – Лира Насыйбуллина. «Мирас» төркеменең тулылыгын кимәнәсез, Лираның нәфис бармаклары, йөрәге аша узган дөрес төзелгән аккордларсыз күз алдына да китерә алмыйм. Бәрмә коралларда – Максим Куприянов. Җырчыларның уңышлы чыгышы Максимның көченә, тырышлыгына, сиземләвенә бик нык бәйләнгән. Монда нечкә тоемлау булганда гына, музыкада нәрсә хакында сөйләнүен бик нык төшенгәндә генә тамашачы күңеленә кереп яшәрлек музыка тудырып була. Максимда боларның барысы да бар. Егетнең махсус белеме, тәҗрибәсе, сәнгать җитәкчесе Рөстәмнең ярдәме акыллы итеп эшкә җигелгән. Гитара татар көйләре, бигрәк тә халык җырлары өчен ят уен коралы кебек тоела. Электән гитара безнең музыкада күп кулланылмаган. Әмма дөнья үзгәрештә, ул гел яңарыш сорый. Шуңа инде без хәзер бу уен коралын сәхнәдә бик еш күзәтәбез. Бас-гитара Руслан Сафин кулында елады, сыкрады, тетрәтте һәм юатты. «Мирас» ансамбленең тулы тавышлы, киң диапазонлы булып яңгыравында Русланның хезмәте хөрмәткә лаек.

Ансамбльнең исеме дә матур, күңелгә җылылык, өмет биреп тора. Борынгы бабаларыбыздан мирас итеп калдырылган халкыбызның күпме җырларын, музыкаль әсәрләрен, милли йөзебезне саклап калырга тырышып җырлаган җырчыларыбыз Рәшит Ваһапов, Илһам Шакиров, Фәридә Кудашева, Усман Әлмиев, Хәйдәр Бигичев, Шамил Әхмәтҗанов, Ания Туишева һәм башка бик күп сәнгатькәрләр репертуарын сәхнәдә яшәтеп, киләчәк буыннарга да җиткерергә, язмаларда калдыру – «Мирас» ансамбленең тоткан кыйбласы, яшәү рәвеше. Бүгенге яшь сәнгатькәрләр белән сәхнә тоту, яшьләргә ярдәмгә килү, репертуар тупларга булышуны «мирас»лылар үзләренең бурычы дип саный. Югарыда телгә алынган юбилей кичәсендә Филүс Каһиров, Рөстәм Асаев, Рәфинә Ганиуллина, Аршак Алтунян, консерватория студентлары, атаклы җырчылар – үзешчәннәр бер кочакта, бер авазда булдылар.

«Мирас»лылар Татарстан Республикасы Халыклар дуслыгы йорты канаты астында яшиләр. Күпме әйтелде инде бу хак сүз: «Бөтен нәрсә шәхесләрдән тора». Дуслык йортының җитәкчесе Ирек Шәриповның акылы, тәвәккәллеге «Мирас» ансамбленә иҗат итәргә җим сибеп торганын әйтми мөмкин түгел. Чөнки ансамбльгә «оя корып» торучы булмаса, без аның ун еллык юбилеен күрә алуыбызга бик шикләнәм. Хөкүмәтебез халыклар дуслыгына, сәнгатькә, милләтләр иҗаты үсешенә зур игътибар бирә. Бу бик сөенечле фал. Залда Дәүләт Советы рәисе Фәрит Мөхәммәтшинның: «Афәрин!» – дип шатланып утырганын күргәч, сәхнәдәге чыгышын, тәбрикнамәсен ишеткәч, «Ходайга шөкер, сәнгатькә, иҗатчыларга зур хөрмәт белән яшәгән шәхесләребез дә бар бит», – дип сөенеп куясың. Бер генә сәяси трибуна, сәяси җөмлә дә дөнья халыклары дуслыгын тотып тору өчен сәнгатьтәге көчкә тиңләшә алмый. Танклар, сәясәтчеләр үтеп керә алмаган иң четерекле почмакларга югары сәнгать көче генә үтеп керә ала. Моны тарих исбатлап килә. Сталин, Хрущев, Брежнев заманнарында дөнья сәясәтен тигезләп-җайлап торганда, күңел йомшарту чарасы итеп гасырлар буе Мәскәүнең Зур театрына чит ил башлыкларын кунак итеп йөрттеләр. Җир шарында, Россиядә, республикабызда халыклар дуслыгы җебе ныгысын өчен, «Мирас» ансамбленең 10 еллык хезмәте тиңдәшсез. «Мирас»лылар: «Җыр, моң, бию, музыка аша саклыйк җиребезне, дуслыгыбызны», – дип дәшә.

Моң дигәннән. Без татар халкы моңнан яралган, диергә яратабыз. Шулайдыр, бәхәсләшмим. Әмма барлык халыкларда да бар моң, һәр халыкның үз моңы. Әрмән егете Аршак Алтунянның туган авыл турындагы әрмән телендә җырланган сагышлы җыры дудук дип аталган музыка уен коралына кушылып башкарылды. Әрмән дудугы – тынлы музыка уен коралы. Аннан чыккан моңлы аваз җанны, йөрәкне телгәли. Аршакның чыгышын дистәләгән барлык катнашучылар сәхнә артында ябырылып, күз яшьләре белән тыңладык. Бик музыкаль, талантлы әрмән егете зал белән бергә, дудукка кушылып саф татарча бөтенләй башка яңгырашта «Ай, былбылым»ны җырлаганда ничек сөенмисең инде. Руслан Сафин Майкл Джексон репертуарыннан «Җиребезне саклыйк» әсәрен тамашачыга инглиз телендә бөтен фаҗигасе, проблемалары белән (мониторда хроника барды) җиткерде. Бөтен эчтәлек Русланның эчке януында, матур тембрлы көчле тавышында һәм экранда сөйләнде. Бернинди дә тәрҗемә кирәк түгел.

Кичәдә Айдар Фәйзрахманов җитәкләгән фольклор төркеме концерт программасын баетып, киңәйтеп, зур профессиональ югарылыкка күтәреп торды. Ике жанрдагы ике ансамбльнең иҗади дуслыгына таҗ куелды. Тамашачы бәхетле иде. «Мирас»лылар аерым чыгышларында халыклар көйләрен, чит ил музыкасын, төрле милләт җырларын нәкъ милли авазларда, нәфисләгән, тәмен җуймый, милли бизәкләрен имгәтми башкардылар. Нотадан уйнауның кыенлыгы юк, әмма милли музыканың җанын тою, сулышын, йөрәк тибешен күрсәтү җиңел түгел. Кеше җаны – иң нечкә корал. Һәр милли музыканың үз тетрәп торган җаны бар. Аны тою, бер сулыштан сулап, күз карашыннан сүзсез аңлау дәрәҗәсенә үсәргә кирәк. «Мирас» ансамбленең иң зур казанышы менә шушы кыйммәткә ирешә белүдә. Алар музыка аша җаннардан җаннарга, нинди милләттән булуына карамастан күчә һәм шунда яшәп калырга омтылалар.

Фердинанд СӘЛАХОВ,
Татарстанның халык артисты.

Илдар Мөхәммәтҗанов фотолары

ЯНСУАРНЫ без дә яраттык

Редакция уздырган конкурс-бәйгеләр һәрвакыт укучыларыбызда яклау таба. Шул рәвешле араларыбыз тагын да якыная. Узган елда үткәрелгән «Безнең авыл» фотобәйгесе моның шулай икәнен кабат раслады. «Шәһри Казан» вәгъдә иткән җырчылар белән бергәләп, узган ел ук инде җиңүче авылларның кайберләрендә: Балык Бистәсе районы Югары һәм Түбән Тегермәнлек, Яшел Үзән районының Бакырчы авылларына барып, чын мәгънәсендә бәйрәм ясап кайтты. Чират әлеге конкурста 142433 тавыш җыеп, икенче урын яулаган Питрәч районы Янсуар авылына да җитте.

Берничә ел элек ябылган мәктәптә хәзер бер түбә астында җирле үзидарә советы, элемтә бүлеге һәм китапханә эшли икән. Безне шушы бинаның ишек төбеннән үк милли киемнәр кигән ханымнар керәшеннәргә хас кунакчыллык белән каршы алды. Көннең буранлап торуына карамастан, халык шактый җыелган иде.

Очрашуны хуҗалар үзләре башлап җибәрде. Авыл тарихы белән таныштырдылар, йолаларын, бәйрәм-уеннарын җырлап-биеп күрсәттеләр. Юлда килгәндә үк бу шигъри яңгырашлы авыл атамасы нәрсә аңлата икән дигән идек.

– Бу мәсьәләдә галимнәрнең үз фаразлары бар, бай тарихлы авылның исеме янында суар дәүләте сугышчылары туктап торган, шуннан килеп чыккан, дип аңлаталар. 1722 елның 24 сентябрь документларында Нырсуар (беренче исеме шулай) авылы турында да мәгълүмат булган. 1859 елда Нырсуар авылында 124 хуҗалык булуы хакында язылган тарихи документлар да бар. 1863 елның 14 июнендә авылда бик каты янгын чыга һәм 70ләп хуҗалыкны юк итә. Янгыннан соң авыл көч-хәл белән булса да торгызыла. 1868 елның 1 октябрендә Янсуарда башлангыч училище, тора-бара хатын-кызлар мәктәбе дә ачыла...

Китапханә мөдире Рәисә Семенова сөйләгәннәрдән без Янсуарның шактый фаҗигале тарихы һәм аның авырлыклар алдында куркып калмый торган кыю халкы турында күп кенә мәгълүмат алдык. Аннары авылның данлыклы «Мишә» ансамбле бизәде очрашуыбызны. Иң өлкән җырчылары Наталья Ярхамовага 72 яшь булса, иң яшь дигәннәре дә 50гә җитеп килә торган ханымнарның һәр чыгышыннан үзләренең авылларын, җырлы уеннарын, йолаларын яратулары сизелеп торды. Хәер, без моны алдан ук шулай икәнлеген чамалаган идек инде. Әгәр дә туган авылларын ярату, аның белән горурлану, яхшы данын дөньяга чыгару теләге булмаса, җиңүчеләр арасына ничек керә алыр иде икән ул кечкенә Янсуар?! Бәйгегә туган авылы күренешләре төшкән фотоларны Римма Семенова белән Эльмира Токранова җибәргәннәр һәм алар бөтен танышларын, туган-тумачасын, белгәнен-белмәгәнен дә үзләре «элгән» фото өчен интернетта тавыш бирергә өндәгән. Казанда яшәсәләр дә, күңелләре туган авыллары белән өзелмәс булып бәйләнгән кызларның. Балалар бакчасында эшләүләрен белгәч, тагын бер сөенеп куйдык. Туган якны ярату хисен үзләре тәрбияли торган сабыйлар күңеленә дә салачак алар, димәк. Җиңүчеләргә дип махсус әзерләнгән дипломнарны газетабызның баш мөхәррир урынбасары Расиха Исмәгыйлова тапшырды.

Бәйгеләрегездә алга таба да бик теләп катнашачакбыз! – диделәр янсуарлылар.

Җыелган халыкка газетабыз күтәргән темалар турында да, гомумән редакциябез турында бәйнә-бәйнә сөйләдек. Бу авылда үзебезнең абунәчеләребез дә булуы безнең өчен аеруча кыйммәт иде.

Янсуарлыларның оптимизмы шаккатырды. Авылда беренче ярдәм күрсәтүче фельдшер да, медпункт та юк икән. Аның каравы, өлкәннәрне бергә туплый, күңелләрне яшь килеш саклый торган «Мишә» фольклор ансамбле бар һәм ул гөрләп эшли. Авылның мәдәният йорты мөдире Анастасия Примерова, мәдәният йортының сәнгать җитәкчесе Вера Малова, Роза Алексеева, Галина Таланова «Евровидение»дә катнашкан «Буран әбиләре»ннән бер дә ким түгел, җырлыйлар да, бииләр дә, төкерәләр алар дөньяның авырлыкларына. Шулай уйнап-көлеп гомер итәләр.

Нәрсә күңелгә тиде? Авылда бөтенләй дә мәктәп, бакча яшендәге бер генә бала да юк икән. Авыл ныклап торып картаеп бара дигән сүз инде бу. Үткәне булган авылның киләчәге булмау бик кызганыч, әлбәттә. Ләкин дөньяны белеп булмый. Бәлки, кайчандыр киткәннәр кайтыр да, авыл икенче сулышын алыр. Казанга якын булуы бетүгә бер сәбәп булса, шул ук якын булу кабаттан терелүенә дә шарт булып тормасмы әле?!

Авылның исемен шагыйранә дип атаган идек. Бу тикмәгә генә түгел, каләмдәшебез – талантлы яшь шагыйрә, Муса Җәлил премиясе лауреаты Луиза да Янсуар атамасын үзенең әдәби тәхәллүсе итеп юкка гына алмаган. Туган авылының исемен киләчәккә алып барасы килүедер шагыйрәнең. Туган авылларын ярату хисе буыннардан буыннарга күчеп, бу авыл халкының тамырларында ага, күрәсең. Без Янсуарга кыш көне барсак та, аның болыннарында үскән матур чәчәкләрне дә күргәндәй булдык. Алар башта хатын-кызларның күңелләренә күчкән, аннары ак бүзләргә ал-лы-гөлле җепләр белән чигелгән. Диварга эленгән сөлге-япмалар авыл халкының күңел матурлыгын да, уңганлыгын да күрсәтеп тора. Җиткән кызлар әле дә өлкәннәр ярдәме белән шулай бирнәләрен үз куллары белән әзерләргә тырышалар икән монда.

Очрашуыбыз кызыклы гына түгел, шактый файдалы да булды. Әллә кунаклар килүен белеп, әллә инде болай юлы төшеп кенә, без анда чакта «Госстрах»ның Питрәч филиалы директоры, тумышы белән шушы авылдан булган Геннадий Любов та килеп керде. Ул, үз чиратында, халыкны мал-мөлкәтләрен үзләрендә иминиятләштерергә өндәде, аның өстенлекләре турында сөйләде.

Янсуардагы очрашуыбыз җыр-моңга тагын да баерак буласы иде дә бит, кызганыч, безнең белән барырга вәгъдә биргән Вадим Захаровның кайтмавы иртән генә билгеле булды. Шуңа да күңелнең бер җире китек сыман булды баштарак. Халык та: «Вадим да килә икән», – дип көткән – аягы йөргәне, күзе күргәне – һәммәсе дә шунда иде янсуарлыларның. Җырга-моңга да алар үзләре этәрде очрашуыбызны, рәхмәт яугырлары. Бергәләп тә җырладык, шигырьләр дә сөйләдек. Иманым камил, әле без киткәч тә, «Шәһри Казан» газетасы турында сүз булмый калмагандыр. Ни өчен дигәндә, өйләренә таралышканда, очрашуга килгән һәркемнең кулында «Шәһри» иде.

Йолдыз ШӘРАПОВА.

Яратуларын яшермәделәр

Актерлар йортында Казан дәүләт мәдәният институты профессоры, театр тәнкыйтьчесе, Татарстанның атказанган сәнгать эшлеклесе Ильтани Иляловaның 85 яшьлек юбилеен билгеләп үттеләр.

Ильтани Илялова үзенең бөтен гомерен театр сәнгатен өйрәнүгә һәм аны популярлаштыруга багышлаган шәхес. Аның 14 китабы, 500гә якын мәкаләләре матбугат битләрендә дөнья күрде. Залда барысы да диярлек күренекле артистлар, сәнгатебезнең төрле тармагында хезмәт куючы шәхесләр иде. Юбилярны аягүрә басып алкышлап каршы алдылар.

– Сез ничек итеп шулай яшьлегезне саклап кала алдыгыз? Сез монда иң олысы булсагыз да, иң яше булып күренәсез. Бу залдагы режиссер-укучыларыгызда да Сезнең өлешегез бар, чөнки Сез аларда сәнгатькә мәхәббәт тәрбияли алдыгыз, – диде Фәрит Бикчәнтәев үзенең чыгышында.

Шушы урында Ильтани Илялова: «Әйдәгез, шушы залда минем 90 яшьлек юбилеемда да очрашыйк», – дигән тәкъдимен җиткерде. Камал театры директоры Илфир Якупов Ильтани ханымның студентларына һәрвакыт ышануын, заманында ял итәргә киткәч, үзенең аның фатирында калып торуын искә төшерде. Камаллыларның һәркайсы юбилярга изге теләкләрен ирештерде.

Мәдәният министры урынбасары Эльвира Камалова педагогны тәбрикләгәндә, аны һәрьяклап үрнәк итеп күрсәтте.

Тинчуринлылар Ильтани Иляловaны котлаганнан соң аннан «имтихан» да алдылар.

Язучылар берлеге рәисе Данил Салихов та аның укучыларыннан берсе.

– Минем Ильтани Иляловaны яратуым студент чактан башланды. Сез студентларны имтиханга кат-кат чакырып тилмертмәдегез. Шуңа күрә без Сезгә гомер буе рәхмәтле булдык, – дип сөйләде.

Мәдәният һәм сәнгать институтының театр кафедрасы деканы Руфина Таҗетдинова юбилярны «елъязмачы да, сәяхәтче дә» дип атады.

Институт доценты Раушан Шәриф шулай ук юбилярга сокланудын белдерде. Педагогның шәкертләре Татарстанга гына түгел, Россия буйлап таралуын да әйтеп узды. Ильтани Иляловaны тәбрикләргә Түбән Кама, Әлмәт, Чаллы, Минзәлә һәм башка театрлардан да килгәннәр иде. Тантаналы кичәне дә Ильтани ханымның укучысы, журналист Земфира Гыйльметдинова алып барды.

Люция ХӘБИБУЛЛИНА.

«WORLDSKILLS» КӨНДӘЛЕГЕ

Булат Галиуллин:
«Максатым – Әбу-Даби шәһәре»

Апас районы Әлмәндәр авылы егете Булат Галиуллин Эшче һөнәрләр чемпионатында инде тәҗрибәле кеше. Ул узган ел да төбәк этабында «Балта остасы» белгечлеге буенча I урын яулаган. Ләкин Россия этабындагы ярышларда үзеннән олырак булган хезмәттәшенә юл биргән. Булат, Мәскәүдәге ярышларда конкурстан тыш катнашып, өченче урынга ия булган. Хәзер ул – Россия җыелмасы составында.

– Безне өч айдан өч айга сынап торалар. Әлегә Россия җыелмасында алты кеше, алардан бары берәү генә Әбу-Даби шәһәренә барачак. Бу минем максатым. Узган елны, беренче тапкыр гына катнашканга, каушатты. Быел исә җиңел булды. Карап торучы кешеләр дә аз иде. Быел без «Казан ярминкәсе»ндә түгел, ә Казан төзелеш көллиятендә ярыштык, шуңа читтән килгән кешеләр булмады, – ди егет. (Исегезгә төшерәбез, «WorldSkills» узган мәйданчыклар буенча студентлар һәм мәктәп балалары өчен экскурсияләр дә оештыралар әле.)

Егет үзе Казан коммуналь хуҗалык һәм төзелеш көллиятенең икенче курс студенты. Казан төзелеш институтына укырга керергә дә исәбе бар.

– Туганнарым шушы көллиятне тәмамлады, хәзер аларның үз төзелеш оешмасы бар. Укырга кергәнче үк үземнең кайда эшләячәгемне белә идем инде. Эшче куллар һәрвакыт кирәк. Ярышларда бакчасарай түбәсен (беседка) җыярга кирәк иде. Барысын да җиренә җиткереп башкарып чыктым. Көллияттәге укытучыларның тырышлыгы бу. Иң актив студентларга директор акчалата да ярдәм итә, – ди Булат.

Егетнең максаты Әбу-Даби белән генә чикләнми, 2019 елда үзебездә узачак чемпионатта җиңү яулау аның исәбе. Булат көллияттә бары тик «5»кә генә укый. Инженер графикасы, физика фәннәре буенча республика олимпиадаларында да катнаша.

Республика этабында Булат **546** балл җыйган.

Газиз Хәсәнов:
«Күз тидерерләр дип куркам»

Казан төзелеш көллиятенең өченче курс студенты Газиз Хәсәновны «WorldSkills» чемпионатының республика этабында I урын алганнан соң урамда да таный башлаганнар. Туган авылы Зур Сәрдектә дә (Кукмара районы), көллияттә дә күзгә күренеп абруе арткан. Моңа гаҗәпләнәсе дә түгел, чөнки Газиз «Республиканың иң яхшы кирпеч салучы белгече» дип табылды бит.

– Әти дә, бабам да мич чыгаручы. Минем дә шушы юлдан китәсем килде. Элек-электән бу һөнәрнең дәрәҗәсе зур. Хәзер йортларга газ кертелсә дә, әледән-әле мунча мичләре, өйгә каминнар чыгаруны сорап торалар. Керемле эш, – ди егет.

Ә чемпионатта җиңү яулар өчен аңа ике ел тир түгеп эшләргә, өйрәнергә туры килә. Хәзер исә апрель аенда булачак Мәскәү янындагы ярышларга әзерләнә.

– Чемпионат вакытында 22 сәгать дәвамында өч төрле бирем эшләргә туры килде. Бездә иң мөһиме – үлчәмнәр дөрес булу. 1 миллиметр ялгышсаң – 0,1 балл, бер сантиметр ялгышсаң, 1 баллыңнан колак кагасың. Чемпионаттан соң игътибар шулкадәр артты, күз тидерерләр дип куркам хәтта, – дип елмая егет.

Газизнең кызыксынулары уку белән генә чикләнми. Футбол, хоккей уйнарга да вакыт таба. Йөргән кызы да бар. Ләкин гаилә корганчы, аягында нык басып торасы килә аның.

– Карьерага ирешмичә, гаилә корып булмый. Ир кешегә эшле булу кирәк, – дигән фикердә ул.

Республика этабында Газиз **543** балл җыйган.

Алисә САБИРОВА.

Галим булып туалармы?

Бу сорауга җавапны табуы бик кыен, аны һәркем үзенчә аңлый. Берәүләр: «Юк, тумыйлар, булалар», – ди. Икенчеләр: «Даһи булып туалар, бар нәрсә нәселдән бирелә», – дигән фикердә. Бер процент таланттан, 99ы – хезмәттән, дип уйлаучылар да бар. Гади генә әйткәндә, акыллы кешеләрдән сәләтле балалар туа, алар гыйлем туплап, галим була, әмма барысы да түгел, билгеле.

Бүгенге көнебезне галимсез күз алдына да китерә алмыйбыз, чөнки таң аткан саен, Җир шарында яңа алым-ысуллар тумый икән, бер генә өлкә дә үсә алмаячак. Һәм, әлбәттә, бу очракта мәгарифнең яшь буынны укыту-тәрбияләү өлкәсе аерым игътибарга лаек. Укытучы булу – гомерлеккә белем илендә яшәп калу дигән сүз. Анда яшәү өчен исә гаять зур түземлелек, эш сөючәнлек, пөхтәлек, җыйнаклык һәм тагын бик күп шундый сыйфатларга ия булу таләп ителә. Бәлки шуңа да, укытучы булып туарга кирәк дип әйтәдер халык. Димәк, мондый олуг исемгә лаек булу өчен күп укырга, педагогик осталыгыңны даими арттырырга, камилләштерергә кирәк. Һәм, әлбәттә, яшьләрне ярату, алар белән аралашудан тәм табу, бөтен гомереңне шул изге эшкә багышлау зарур. Бүген сүзебез әнә шул сыйфатларга ия булган психология һәм мәгариф институтының яшь галиме, педагогика фәннәре кандидаты Илнар Яруллин хакында.

Ул урта мәктәпне тәмамлаганнан соң Казан дәүләт педагогика университетының математика факультетына укырга керә. Аны уңышлы тәмамлап, аспирантурада белем ала. Бүгенге көндә ул укыту һәм тәрбияләү методологиясе кафедрасында хезмәт куя. Фәнни журналларда, шулай ук чит илләрдә мәкаләләрен даими рәвештә бастырып чыгара, конференцияләрдә катнаша.

Университетта укыту дәверендә Илнар Яруллин студентлар белән эшләүнең үз алымнарын булдырган. Студентлар материалны ятлап вакыт уздырмасын, ә укытучы сөйләгәннәрне аңнарына сеңдереп барсын, фәннең асылын аңласын иде дигән фикердә ул.

Яңа технологияләр кулланып, заманча дәресләр үткәргәне, студент тормышында булган проблемаларны аңлап эш итүе өчен, университетта аны бик ихтирам итәләр. Фәнни эшчәнлеге өчен университет җитәкчелегенең, Мәгариф һәм фән министрлыгының Мактау грамоталары белән күп тапкырлар бүләкләнгә ул.

Гыйнвар азагында, психология һәм мәгариф институтының гыйльми шурасы карары нигезендә, Илнар Яруллин укыту һәм тәрбияләү методологиясе кафедрасы доценты итеп билгеләнде. Киләчәктә дә яшь галим яңадан-яңа уңышларга ирешсен, милләтебез горурланырдай шәхес булсын иде. Уңышлар аңа!

Әнвәр ХУҖИӘХМӘТОВ,
Рәмис НАСЫЙБУЛЛОВ.

«Мама» урынына «ӘНИ» дип дәшәрләр иде

Уралда ябык режимлы шәһәрдә яшәп кайтканнан соң, Татарстанда чыга торган ана телендәге һәр басмага, һәр тапшыруга сусаган иде күңел. Күп кенә татар басмаларын рәхәтләнеп укыдым, Казанда Габдулла Кариев исемендәге Татар дәүләт яшь тамашачы театрына яратып йөрим. «Нигез ташлары», «Кичер мине, әнкәй» спектакльләрен караганда тамакка төер, күзгә яшь тыгыла иде. Артистлар искиткеч уйныйлар, һәрберсе талант. Театр труппасын берләштереп торучы талантлы режиссер Ринат Әюповка да бик рәхмәтлемен. Кызганыч, үз биналары юк икән. Ярдәм итсеннәр иде аларга. Ул чагында бу театрга кеше дә күбрәк йөри башлаячак. Кайбер балалар да Җәлилне Тукайдан аерырга, «мама» урынына «әни» дип дәшәргә өйрәнер иде.

Шамил БИБАРЦЕВ,
Казан.

Вниманию руководителей промышленных и сельскохозяйственных предприятий, организаций, индивидуальных предпринимателей, других землепользователей и частных лиц!

По территории районов Республики Татарстан проходят трассы магистральных газопроводов и газопроводов-отводов высокого давления, эксплуатируемые ООО «Газпром трансгаз Казань», по которым осуществляется поставка природного газа промышленным и сельско-хозяйственным предприятиям, населению и другим категориям потребителей.

Трассы газопроводов нанесены на карты землепользования районов Республики Татарстан и непосредственно обозначены на местности опознавательными знаками.

ГАЗОПРОВОД – ИСТОЧНИК ПОВЫШЕННОЙ ОПАСНОСТИ, ВОЗНИКНОВЕНИЯ ВЗРЫВОВ И ПОЖАРОВ.

«Правилами охраны магистральных трубопроводов», утвержденными Минтопэнерго РФ 29.04.1992, Постановлением Госгортехнадзора РФ от 22.04.1992 № 9, в целях исключения возможных повреждений трубопроводов установлены **ОХРАННЫЕ ЗОНЫ** трубопроводов в виде участка земли, ограниченного условными линиями, проходящими в 25 м от оси трубопровода, с каждой стороны.

В охранных зонах трубопроводов всем лицам и организациям запрещается производить всякого рода действия, которые могут нарушить нормальную эксплуатацию трубопроводов либо привести к их повреждению, в частности:

■ перемещать, засыпать и ломать опознавательные и сигнальные знаки, контрольно-измерительные пункты;

■ открывать люки, калитки и двери необслуживаемых усилительных пунктов кабельной связи, ограждений узлов линейной арматуры, станций катодной и дренажной защиты, линейных и смотровых колодцев и других линейных устройств, открывать и закрывать краны и задвижки, отключать или включать средства связи, энергоснабжения и телемеханики трубопроводов;

■ устраивать всякого рода свалки, выливать растворы кислот, солей и щелочей;

■ разрушать берегоукрепительные сооружения, водопропускные устройства, земляные и иные сооружения (устройства), предохраняющие трубопроводы от разрушения, а прилегающую территорию и окружающую местность – от аварийного разлива транспортируемой продукции;

■ бросать якоря, проходить с отданными якорями, цепями, лотами, волокушами и тралами, производить дноуглубительные и землечерпальные работы;

■ разводить огонь и размещать какие-либо открытые или закрытые источники огня.

В охранных зонах трубопроводов без письменного разрешения предприятий трубопроводного транспорта запрещается:

■ возводить любые постройки и сооружения;

■ высаживать деревья и кустарники всех видов, складировать корма, удобрения, материалы, сено и солому, располагать коновязи, содержать скот, выделять рыбопромысловые участки, производить добычу рыбы, а также водных животных и растений, устраивать водопои, производить колку и заготовку льда;

■ сооружать проезды и переезды через трассы трубопроводов, устраивать стоянки автомобильного транспорта, тракторов и механизмов, размещать сады и огороды;

■ производить мелиоративные земляные работы, сооружать оросительные и осушительные системы;

■ производить всякого рода открытые и подземные, горные, строительные, монтажные и взрывные работы, планировку грунта.

■ производить геолого-съемочные, геолого-разведочные, поисковые, геодезические и другие изыскательские работы, связанные с устройством скважин, шурфов и взятием проб грунта (кроме почвенных образцов).

Кроме того, сводом правил «СП 36.13330.2012. Свод правил. Магистральные трубопроводы. Актуализированная редакция СНиП 2.05.06-85*», утвержденным приказом Госстроя России от 25.12.2012 № 108/ГС, установлены **ЗОНЫ МИНИМАЛЬНО ДОПУСТИМЫХ РАССТОЯНИЙ** от осей газопроводов до населенных пунктов, отдельных промышленных и сельскохозяйственных предприятий, зданий и сооружений, отдельно стоящих нежилых и подсобных строений, гаражей и открытых стоянок для транспорта, коллективных садов, автомобильных, железных дорог и других объектов. Зоны минимально допустимых расстояний определяются в зависимости от класса и диаметра газопровода, степени ответственности объектов и служат для обеспечения безопасности этих объектов.

Застройка зон минимально допустимых расстояний до газопроводов не допускается. Здания, строения и сооружения, построенные ближе установленных строительными нормами и правилами минимальных расстояний до объектов систем газоснабжения, подлежат сносу за счет средств юридических и физических лиц, допустивших нарушения.

Магистральные газопроводы и газопроводы-отводы высокого давления являются взрывопожароопасными объектами повышенного риска, их безопасность находится под постоянным контролем всех заинтересованных служб. Нарушение правил безопасности в охранной зоне и в зоне минимально допустимых расстояний газопроводов чревато серьезными последствиями. В безопасной эксплуатации объектов системы газоснабжения должны быть заинтересованы не только соответствующие службы, но и все жители Республики Татарстан.

За нарушение правил безопасности предусмотрена административная ответственность, а в случае причинения тяжкого или средней тяжести вреда здоровью человека либо в случае причинения крупного ущерба наступает уголовная ответственность.

Органы исполнительной власти и должностные лица, граждане, виновные в нарушении правил охраны магистральных газопроводов, газораспределительных сетей и других объектов систем газоснабжения, строительстве зданий, строений и сооружений без соблюдения безопасных расстояний до объектов систем газоснабжения или в их умышленном блокировании либо повреждении, иных нарушающих бесперебойную и безопасную работу объектов систем газоснабжения незаконных действиях, несут ответственность в соответствии с законодательством Российской Федерации.

Перед началом строительных работ предприятия, организации или отдельные граждане, производящие эти работы, обязаны получить письменное разрешение эксплуатирующей организации на производство работ в охранной зоне и в зоне минимально допустимых расстояний газопроводов по установленной форме.

Производство работ без разрешения или по разрешению, срок действия которого истек, запрещается.

Для получения точной информации о местоположении магистральных газопроводов и газопроводов-отводов необходимо письменно обратиться в ООО «Газпром трансгаз Казань»: факс **(843) 264-57-02**, e-mail: **info@tattg.gazprom.ru**

При обнаружении утечек газа или других неисправностей на магистральных газопроводах и газопроводах-отводах просим сообщить местному органу власти, а также эксплуатирующей организации ООО «Газпром трансгаз Казань» по адресу: 420073 РТ, г. Казань, ул. Аделя Кутуя, 41, круглосуточный телефон диспетчерской службы: (843) 264-58-12 или по телефону экстренной службы: 04.

БУДЬТЕ ВНИМАТЕЛЬНЫ И ОСТОРОЖНЫ ВБЛИЗИ ТРУБОПРОВОДОВ!

Реклама

Әйдәгез узышабыз!

Һава торышы салкын тору сәбәпле, Казанда «Россия чаңгы юллары – 2017» спорт чарасы 18 февральгә күчерелде.

Дамир БӘДРИЕВ

Дамир Бәдриевнең фотоархивыннан

«Россия чаңгы юллары» чаңгыда массакүләм узышлар, гадәттә, 11 февральдә оештырыла. Ул илебезнең 72 шәһәрен колачлый. Россия күләмендә узган ел массакүләм чаңгы узышларында 1,5 миллион кеше катнашкан. Шуларның 99 процентының чаңгы спортына гомумән дә мөнәсәбәте юк икән. Болар: чаңгыда шуарга яки актив ял яратучы балалар, укучылар, студентлар, өлкәннәр һәм VIP-затлар.

«Россия чаңгы юллары» массакүләм узышлары инде 35нче мәртәбә үткәрелә. Республикада узган ел, «Россия чаңгы юллары» спорт чарасына теләктәшлек йөзеннән, «Татарстан чаңгы узышлары»нда 170 мең кеше катнашкан. Казанда – 21 мең, Чаллыда 20 мең кеше чаңгыга баскан.

– Казан сан һәм сыйфат ягыннан илнең спорт башкаласы булуын раслап тора. Якташларыбыз соңгы вакыттагы халыкара спорт бәйгеләрендә 29 призлы урынны яулады. Казанлыларның 40 проценты физкультура һәм спорт белән даими шөгыльләнә, бу чик түгел. Ишегалды спортын үстерергә, талантлыларны шуннан сайлап алырга кирәк, – диде мэр Илсур Метшин шәһәр Башкарма комитетында узган киңәшмәдә һәм казанлыларны массакүләм чаңгы узышларында актив катнашырга чакырды.

Казан шәһәре Башкарма комитеты хәбәр итүенчә, 18 февральдә массакүләм чаңгы узышлары өч урында була. Болар: Юдино бистәсендәге «Локомотив» стадионы, Горки-Әмәт урман паркы, Яңа Савин районында Гаврилов урамы буенча Казансу елгасы яры.

Узышларда катнашырга теләүчеләр башлык һәм старт номеры алырга тиеш. Моның өчен мандат комиссиясенә шәхесне раслый торган документ, табибтан рөхсәт белешмәсе яки сәламәтлегеңә шәхси җаваплылык алу турындагы язу тапшыру зарур. Мандат комиссиясе «Хезмәт резервлары» (Николай Ершов урамы, 7а) стадионында урнашкан. Ул 11 февральне дә кертеп, 13.00-18.00 сәгатьләрдә эшли.

БЕЛЕШМӘЛӘР ӨЧЕН ТЕЛЕФОННАР:

Авиатөзелеш һәм Яңа Савин районы (843) 519-34-45, 519-34-58;

Совет районы (843) 272-31-73, 272-06-42, 272-01-05;

Вахитов һәм Идел буе районы (843) 277-10-72;

Киров һәм Мәскәү районы (843) 557-76-45;

«Хезмәт резервлары» стадионы (843) 236-31-63;

Физкультура һәм спорт комитеты (843) 236-20-39.

ПОКУПАЙТЕ ПРЯМО СЕЙЧАС!
с 7 по 28 февраля 2017 г.
бережная аптека®
Звонок на телефон горячей линии по всей России бесплатный: 8-800-700-95-43

При болях в горле
Лизобакт №30 таб. д/рассас. — 249 руб.

От изжоги
Алмагель А 170мл фл сусп.д/пр внутрь — 184 руб.

Для улучшения пищеварения
Креон-10000 150мг №20 капс.киш/раств. — 258 руб.

Лечение заболеваний носа
Ринофлуимуцил 10мл фл. спрей наз. — 228 руб.

Для лечения кашля
Амбробене 30мг №20 таб. — 122 руб.

Болеутоляющее, противовоспалительное средство
Миг 400мг №10 таб. п/о/плен — 61 руб.

Успокоительное средство
Тенотен №40 таб. д/рассас. — 174 руб.

Лечение заболеваний носа
Риностоп 0,1% 15мл фл спрей наз. — 78 руб.

Профилактика инфаркта миокарда
Тромбо АСС 100мг №28 таб.п/о/пл/киш-раств — 41 руб.

Снятие боли и спазма
Но-шпа 40мг №24 таб. — 164 руб.

ИМЕЮТСЯ ПРОТИВОПОКАЗАНИЯ. НЕОБХОДИМО ПРОКОНСУЛЬТИРОВАТЬСЯ СО СПЕЦИАЛИСТОМ

На товары, участвующие в акции, дополнительные скидки не распространяются. Предложение действительно при наличии акционных товаров. Количество товаров ограничено. Не более 3 упаковок в одни руки. Изображение товаров может отличаться от представленных в аптеках. С информацией об организаторе акции, о правилах ее проведения, акционных товарах, сроках, месте и порядке их приобретения, можно ознакомиться на сайте www.farmaimpex.ru.

Реклама

Илдар Мөхәммәтҗанов фотосы

Батырлар җыелган җирдә

Бүген Зәй шәһәрендә каһарман шагыйрь Муса Җәлил истәлегенә «Ватаным Татарстан» газетасы тарафыннан гамәлгә куелган 54нче милли көрәш бәйгесе башланды. Бу уңайдан кайчандыр келәмдә бил алышкан Татарстанның яшьләр эшләре һәм спорт министры беренче урынбасары Хәлил Шәйхетдинов, «Ак Барс» көрәш сарае директорының беренче урынбасары, Татарстанның атказанган тренеры Фәрит Шәйхетдинов та үзләренең спортта алган җәрәхәтләре, җиңүләре һәм җиңелүләре турында искә төшерде.

Турнир ике көн дәвам итәчәк. Анда Россия төбәкләреннән 500гә якын иң көчле спортчы катнаша. Араларында Ренас Кәлимуллин, Раил Нургалиев, Илдар Гыйниятуллин, Рамил Синякаев, Азат Нурмөхәммәтов, Эльдар Хәмитов кебек батырларыбыз да бар.

Турнир Зәйдә икенче тапкыр оештырыла. Әлеге мәйдан очраклы гына сайланмады. Хәлил Шәйхетдинов сүзләренчә, биредә бүген спортның «перезагрузка»сы башланды. 1997 елда ул үзе дә монда бил алышкан. Муса Җәлил турниры көтелмәгән вакыйгаларга бай. Кечкенә генә авылдан килгән спортчы да моннан батыр булып китә ала. Шуңа да спортчылар аны үзара «Татарстанның Олимпия уеннары» дип йөртә. Ә әһәмияте ягыннан ул республика чемпионатын да уздыра.

Фәрит Шәйхетдинов турнирда беренче тапкыр моннан 45 ел элек бил алышкан. Тренер буларак та тәҗрибәсе зур.

– Бу турнир – көрәшчеләр өчен иң зур вакыйгаларның берсе. Әле дә хәтерлим, Питрәч районыннан килгән яңа гына армиядән кайткан бер егеткә шушында җиңелгән идем. Ун секунд кала, мине чистага салып бәрде. Ул Михаил Минаев иде, хәзерге вакытта тренер булып эшли, – дип хатирәләре белән уртаклашты Фәрит Шәйхетдинов.

Ә Хәлил Шәйхетдинов Муса Җәлил турнирында хәтта теш казналыгын имгәткән булган.

– 1990 еллар иде, Кукмара районында ярышабыз. Каты бәрелгәннән соң табибка мөрәҗәгать итәргә туры килде. Теш казналыгым чыгуы ачыкланды. Алга таба көрәштермиләр, бирел, диләр. Мин риза булмадым. Тагын келәмгә чыктым. Шунда көндәшемне балл буенча җиңгән идем. Кечкенәдән көрәш белән чынығып үскән бала беркайчан да тормышта югалып калмый, – ди ул.

Турнир районнар буйлап күчеп йөри. Ләкин 500гә якын спортчыны һәр район да тиешле дәрәҗәдә кабул итә алмый. Шуңа да бу – спортчылар өчен генә түгел, район җитәкчеләре өчен дә зур сынау. Һәр район Муса Җәлил турнирын үзендә үткәрә алуны зур дәрәҗәгә саный.

Гомумән, республика буенча 30 мең кеше милли көрәш белән шөгыльләнә. Хәлил Шәйхетдинов әлеге спорт төрен, самбо, бадминтон кебек үк, физкультура дәресе кысаларына кертергә кирәк, ди. Министр урынбасары сүзләренчә, тиздән республикада көрәшчегә һәйкәл дә ачылачак икән. Аның эскизлары инде әзер ди.

– Республика җитәкчеләре ярдәме белән, сигез иң яхшы көрәшчене үзара ярыштырасым килә. Беренче урынга – фатир, икенчесенә машина бүләк итәрлек булсын ул. Казахстанда көрәшне шундый зур бүләкләр белән генә күтәрделәр. Көрәш аларда үзе бер шоу. Һәр спортчы келәмгә җанвар тиресе белән чыга. Җиңүче үз тиресен дә, көндәшенекен дә алып китә. Безнең иганәчеләр күп, республикабыз көчле, аны гына булдырабыз, – диде Хәлил Шәйхетдинов.

Алисә САБИРОВА.

ХАТЫН-КЫЗЛАР КӨРӘШЕНӘ НИЧЕК КАРЫЙСЫЗ?

Хәлил Шәйхетдинов:

– Ата кеше буларак, кызларымны көрәшкә дә, авыр атлетикага да бирмәс идем. Хатын-кызларга җиңел, нәфис спорт килешә. Аларның бит әле ана буласылары бар. Ләкин көрәшче холыклы кызлар бар. Көчләрен кая куярга белми йөргәнче, республика, ил данын төрле ярышларда якласалар яхшырак. Һәркем үзе яраткан эш белән шөгыльләнергә тиеш. Шуңа да бу бәхәсле сорау. Бүген Россия җыелмасында ил данын 29 Татарстан кызы яклый. Хоккей да кызлар спорты түгел. Ләкин хатын-кызлар арасында Россия хоккей командасында Ольга Сосина, Фәнүзә Кадыйрова, Лиана Ганиева кебек безнең кызлар уйный.

Миңназыйм Сәфәров, «Ватаным Татарстан» газетасы баш мөхәррире:

– Эмансипация хатын-кызларны ирләр белән көрәшергә этәрәдер инде ул. Ләкин мин мондый әйбергә каршы. Гүзәл зат иренең көчле җилкәсе артында качып торырга тиеш. Шоу өчен дә моны эшләргә кирәкми.

Фәрит Шәйхетдинов:

– Нинди дә булса спорт белән шөгыльләнү, бернәрсә белән дә шөгыльләнмәүгә караганда, хәерлерәк. Бүген республикада хатык-кызлар көрәшенә дә мөмкинлекләр зур. Өч улым бар, алар барысы да көрәште. Кызлары исә нәфис гимнастика, балет белән шөгыльләнә.

«Татспиртпром» терлекчелек тармагы өчен продукция эшләп чыгаруны арттыра

Компаниянең спирт заводлары, төп продукциядән тыш, терлекчелек предприятиеләре өчен кыйммәтле продукт – бөртекләндерелгән коры барда һәм коры азык чүпрәсе дә җитештерә.

Ашлыкны тирәнтен эшкәртү нәтиҗәсендә, Усад һәм Мамадыш спирт заводлары терлекләр өчен югары сыйфатлы азык компонентлары – бөртекләндерелгән коры барда һәм коры азык чүпрәсе ала. Татарстан ашлыгын иң әре кулланучылардан берсе буларак, «Татспиртпром» җитештерүнең экологик яктан чисталыгы һәм калдыксыз технология белән аерылып тора. Усад спирт заводы исә терлекчелек өчен товарлар эшләп чыгару өлкәсендә флагман. Заводта югарыда атап үтелгән продукция 2015 елның язынннан җитештерелә, ә 2016 елның ахырында ул тулы куәтенә эшли башлады.

– Без моннан ике-өч ел элек хезмәттәшлек итә башладык. Безгә барысы да ошый, бәясе дә кулай. Башка җитештерүчеләрнекенә караганда, әлеге бардада протеин микъдары 2,5 тапкырга күбрәк. Безгә аена 40 тоннага якын барда кирәк, аны беренче тапкыр бозаулаган сыерларның рационына өстибез. Барданы март аена җитәрлек күләмдә сатып алдык инде, алга таба сөйләшүләр алып барачакбыз. Киләчәктә дә сатып алырбыз, мөгаен, бәясе дә кулай, – ди «Бөреле» ЯАҖнең баш зоотехнигы Рамил Мөстәкыймов.

Биредә терлекчелек тармагы өчен Усад спирт заводында җитештерелгән продукцияне бик теләп кулланалар.

Моннан тыш, Мамадыш спирт заводында да авыл хуҗалыгы өчен продукция эшләп чыгаралар. Компаниянең генераль директоры Ирек Миңнәхмәтов завод коллективы белән декабрь аенда узган очрашуда билгеләгәнчә, техник һәм инженерлык мөмкинлекләре филиалның терлекчелек тармагы өчен спирт һәм туклыклы азык җитештерү куәтен ике мәртәбә арттырырга ярдәм итә. Узган елгы күрсәткечләр аеруча куандыра: 2015 ел белән чагыштырганда, коры азык җитештерү – 22, бөртекләндерелгән коры барда эшләп чыгару 87 процентка арткан.

«Татспиртпром» АҖ предприятиеләре терлекчеләрне продукция белән тәэмин итеп кенә калмый, үзләре урнашкан район икътисадының локомотивы да булып тора. Спирт заводлары Мамадыш һәм Биектау районы халкын эш урыннары белән тәэмин итә. Терлекчелек продукциясе Татарстан авыл хуҗалыгы предприятиеләреннән тыш, Россия төбәкләренә, шулай ук чит илләргә дә озатыла.

Реклама

ИЗВЕЩЕНИЕ О ПРОВЕДЕНИИ СОБРАНИЯ О СОГЛАСОВАНИИ МЕСТОПОЛОЖЕНИЯ ГРАНИЦЫ ЗЕМЕЛЬНЫХ УЧАСТКОВ

Кадастровым инженером Латыповым Ниязом Диллусовичем (420075, г.Казань, ул.Главная, д.62/15, эл.почта s2495066@yandex.ru, тел.89270393119, квалификационный аттестат 16-12-503) выполняются кадастровые работы в отношении земельного участка с кадастровым номером 16:50:171659:22, расположенного: Республика Татарстан, г.Казань, Приволжский район, ул.Березниковская 1-я, дом 19.

Заказчик кадастровых работ: Вафин Рашид Наилевич (г.Казань, ул.1-я Березниковская, д.19).

Согласование местоположения границ проводится без установления границ земельных участков на местности путем проведения собрания, которое состоится 15 марта 2017 года в 19 часов 00 минут по адресу: РТ, г.Казань, ул.Главная, д.62/15.

С проектом межевого плана земельного участка можно ознакомиться по адресу: г.Казань, ул.Главная, д.62/15.

Возражения по проекту межевого плана и требования о проведении согласования местоположения границ земельных участков на местности принимаются с 15 февраля 2017г. по 10 марта 2017г. по адресу: 420075, г.Казань, ул.Главная, д.62/15.

Кадастровые номера смежных земельных участков, с правообладателями которых требуется согласовать местоположение границы: 16:50:171659:13 (Республика Татарстан, г.Казань, Приволжский район, ул Березниковская 1-я, д.17), 16:50:171659:47 (Республика Татарстан, г.Казань, Приволжский район, ул. Подлесная, д.16), 16:50:171659:21 (Республика Татарстан, г.Казань, Приволжский район, ул Березниковская 1-я, д.21).

При проведении согласования местоположения границ при себе необходимо иметь документ, удостоверяющий личность, а также документы о правах на земельный участок.

АФИША
13 – 19 ФЕВРАЛЬ

Г.КАМАЛ ИСЕМЕНДӘГЕ ТАТАР ДӘҮЛӘТ АКАДЕМИЯ ТЕАТРЫ
(ТАТАРСТАН УРАМЫ, 1)

Уфа шәһәре рус драма театры гастрольләре
13 февраль «Голубая камея» (К.Кавалерян)
Башлана: 19.00
Билет бәясе: 200-700 сум
14 февраль «Палата бизнес-класса» (А.Коровкин)
Башлана: 19.00
Билет бәясе: 200-700 сум
15 февраль «Бешеные деньги» (А.Островский)
Башлана: 19.00
Билет бәясе: 200-700 сум
16 февраль «Голубая камея» (К.Кавалерян)
Башлана: 19.00
Билет бәясе: 200-700 сум
17 февраль «Снежная королева» (К.Брейтбург, Э.Мельник, С.Сашин)
Башлана: 19.00
Билет бәясе: 200-500 сум
18 февраль «Снежная королева» (К.Брейтбург, Э.Мельник, С.Сашин)
Башлана: 11.00
Билет бәясе: 200-500 сум
18 февраль «Бешеные деньги» (А.Островский)
Башлана: 18.00
Билет бәясе: 200-700 сум
Әлмәт Татар дәүләт драма театры гастрольләре
19 февраль «Сигезле бию» (Р.Сабыр)
Башлана: 12.00
Билет бәясе: 200-250 сум
19 февраль «Качаклар» (Н.Исәнбәт)
Башлана: 18.00
Билет бәясе: 250-500 сум

Г.КАРИЕВ ИСЕМЕНДӘГЕ КАЗАН ТАТАР ДӘҮЛӘТ ЯШЬ ТАМАШАЧЫ ТЕАТРЫ
(ПЕТЕРБУРГ УРАМЫ, 57)

14 февраль «Ширбәт ае» (А.Попов, Х.Ибраһим)
16 февраль «Галиябану» (М.Фәйзи)
Башлана: 18.30
Билет бәясе: 150-200 сум

К.ТИНЧУРИН ИСЕМЕНДӘГЕ ТАТАР ДӘҮЛӘТ ДРАМА ҺӘМ КОМЕДИЯ ТЕАТРЫ
(ГОРЬКИЙ УРАМЫ, 13)

14 февраль «Өзелгән яфраклар» (Р.Габделхакова)
Башлана: 18.30
15 февраль «Күрәсем килгән иде...» (И.Мәхмүтова)
Башлана: 18.30
16 февраль «Кияүләр» (К.Тинчурин)
Башлана: 18.30
17 февраль «Назлы кияү» (К.Тинчурин)
Башлана: 18.30
18 февраль «Сүнгән йолдызлар» (К.Тинчурин)
Башлана: 17.00
19 февраль «Беренче мәхәббәт» (И.Гали)
Башлана: 17.00
Билет бәясе: 250-600 сум

«ӘКИЯТ» КУРЧАК ТЕАТРЫ
(ПЕТЕРБУРГ УРАМЫ, 57)

15 февраль «Бүре җиләге» (Р.Зәйдулла)
Башлана: 13.00
16 февраль «По щучьему велению» (Е.Тараховская)
Башлана: 11.00, 13.00
17 февраль «Золушка» (Ш.Перро)
Башлана: 11.00, 13.00
18 февраль «Новые приключения трех поросят» (Б.Вайнер)
Башлана: 11.00, 13.00
18 февраль «Идет Коза рогатая» (М.Протасова)
Башлана: 11.00
19 февраль «Малыш и Карлсон» (А.Линдгрен)
Башлана: 11.00, 13.00
19 февраль «Су анасы» (Г.Тукай, З.Хәснияр инсц.)
Башлана: 15.00
Билет бәясе: 200-300 сум

Г.ТУКАЙ ИСЕМЕНДӘГЕ ТАТАР ДӘҮЛӘТ ФИЛАРМОНИЯСЕНЕҢ КОНЦЕРТ ЗАЛЫ
(ПАВЛЮХИН УРАМЫ, 73)

13 февраль Ильмира Нәгыймова белән Руслан Кираметдинов концерты
Башлана: 18.30
Билет бәясе: 500-1000 сум
14 февраль Фәйзи Гаскаров исемендәге дәүләт академия халык биюләре ансамбле
Башлана: 18.30
Билет бәясе: 300-800 сум
15 февраль Илһам Шакиров концерты
Башлана: 18.30
Билет бәясе: 350-1200 сум

«ШӘҺРИ КАЗАН» РЕДАКЦИЯСЕНЕҢ КҮРГӘЗМӘЛӘР ЗАЛЫ
(ЧИСТАЙ УРАМЫ, 5)

Фотохәбәрчеләр Илдар Мөхәммәтҗанов белән Шамил Абдюшевның «Чор һәм шәхес» дип аталган фотокүргәзмәсе эшли.
Керү ирекле (эш көннәрендә)

Ризван Хәкимов: «Җырчылар үз-үзләренә кул чаба»

Сабыр холкы, сәхнәдә үз-үзен тыйнак тотышы, күптән халыкныкына әверелгән җырлары өчен ярата аны тамашачы. «Әйтмә син авыр сүз», «Моңнар кайтсын авылга», «Елама, ярсыма», «Балаларга фатиха», «Әйтегезче, ромашкалар» кебек йөзләгән популяр җырларның авторы Ризван ХӘКИМОВ.

– Ризван абый, саубуллашу концертларыгыз бара. Бу ничектер моңсу яңгырый түгелме?

– Матур итеп килгән кебек, жай гына китә дә белергә кирәк. Мин тамашачымнан аерылмыйм бит, композитор буларак иҗат итүемне дәвам итәм. Ә җырчы булып, яшьләр белән ярышып йөреп булмас. Аларга урын бирергә кирәк. Минем әле үз проектларым да бар. Композиторлар фестивале, мәсәлән.

– Композиторлар күптән инде авторлык хокуклары өчен көрәшә. Сезнең җырларны да рөхсәтсез башкаручылар бардыр.

– Башкортстан, Татарстан җырчылары да башкарды, әле дә җырлыйлар, ләкин тавыш күтәргәнем юк. Кайбер авторлар, суд юлында йөреп, дөреслек эзли. Алай итеп йөргәнем булмады. Мөселман диненә кешегә ул килешми дә. Ошый икән, җырласыннар, дим. Хит булып яңгыраган җырларым башкаручыларга бушлай эләкте, хәзер генә ул сатып алу дигән әйбер бар. «Әйтмә син авыр сүз» Татарстандагы сигез җырчының репертуарында диделәр. Казанга бик йөрмим бит, ишетми-белми, диләрдер. Акча түләү турында сүз бармый бит, шалтыратып рөхсәт кенә сорасалар да, күңелем булыр иде.

– Бүгенге төркемегез хакында сөйләп үтсәгез иде.

– Тамашачы хәтерлидер, Нәфисә исән чакта, төркем «Могҗиза» дип атала иде. Төркемгә хәзер аның исемен бирдем. Әмма безнең миссиябез шул ук – талантлы яшьләрне зур сәхнәгә алып чыгу. Төркемдә бик сәләтле егетләр, кызлар эшли. Алар һәрвакыт эзләнүдә, бер урында гына таптанмыйлар. Элек язылган җырларга яңача аранжировка ясап, җырга яңа сулыш бирәләр. Төркемемдәге иң зур терәгем – кызым Альбина.

– Радик Юльякшинның да татар тамашачысы белән нәкъ сез таныштырдыгыз.

– Әйе. Ул елларда Радикның җырлары бик җитди булмаса да, бүген аның эшләре горурлык тудыра. Күрәсең, вакытында минем киңәшләрне дә колагына элгәндер. «Бер көнлек җырлар язып, вакытыңны әрәм итмә», – дигән идем мин аңа. Уфага кайтса, шундук яныма йөгереп керә. Яратып, «Батя» дип йөртә ул мине. Минем «Елама, ярсыма» җырыма ул яңа сулыш бирде.

– Иҗатка килгәндә, бер композиторга башта шигырь кирәк, ул шуңа көй яза, ә кемдер, киресенчә, иҗат итә.

– Мәгънәле шигырь кирәк. Шигырьнең сүзләренә карата бик бәйләнчек мин. Озак еллар Рамил Чурагол белән эшләдем. Хәзер, нигездә, искиткеч шагыйрь, язучы, нәфис сүз остасы Марат Кәбиров белән хезмәттәшлек итәм. Әйткәнемчә, яхшы җыр текстын язучылар бик сирәк! Барлык шагыйрьләр дә җыр сүзләре яза алмый.

Кайбер яшьләр сүзен дә үзе яза, көен дә, аннан үзе чыгып җырлый да. Кагыйдә буларак, аннары кулны да үзенә-үзе чабарга туры килә.

– Сезнеңчә, җыр нинди булырга тиеш?

– Җыр яше дә, карты да яратырлык, табыннарда гөрләтеп җырлап утырырлык булырга тиеш.

– Ни өчен Альбина Хәкимова сольный карьерасын эшләргә ашкынып тормый, үзенең аерым концертларын куймый? Аны һаман да әтисе күләгәсендә генә йөри, дип уйламаслармы?

– «Әти, син сәхнәдә булганда, мин синең янында гына булачакмын», – дип еш әйтә ул. Аңа нинди генә продюсерлар тәкъдим ясамады, Татарстанга да чакырдылар, әмма әлегә ризалашмый. Киләчәктә мин аны «Нәфисә» эстрада-җыр театрының эшен дәвам итүче итеп күрәм.

– Каян илһам аласыз?

– Әлбәттә, халыктан, җырларымны яратып тыңлаучы тамашачымнан. Ул иҗатымны кабул итә икән, миннән дә бәхетле кеше юк! Ә аннары, кызларым, оныкларым дип яшим. Аларның яхшы кеше, тәрбияле булуына сөенеп туя алмыйм. Ике кызым да иҗат юлын сайлады. Илнара, икътисад институтын тәмамлаган булса да, бүген яраткан эше белән шөгыльләнә. Мәскәүдә флорист-дизайнер курсларында укып, бүген йорт эчләрен, кибетләрне бизи, гадәти булмаган букетлар ясый.

– Иҗатыгызда кризислар булдымы? Булса, ничек җиңеп чыктыгыз?

– Андыйны хәтерләмим. Нәфисә үлгәч тә, иҗат бер генә минутка да туктамады. Җыр бит тыныч чакта түгел, йә кайгылы, йә шатлыклы вакытларда туа. Нәфисә истәлегенә бер диск та чыгардым. Анда кергән «Исмәле, җил», «Хәлләрең ничек, дип сорама» җырларын халык аеруча яратты.

Азалия ИСМӘГЫЙЛЕВА.

Шәһри КАЗАН
ИНДЕКСЛАР
П2395 (3 тапкыр чыга)
П2430 (пәнҗешәмбе саны)
П2419 (оешмалар өчен)
www.shahrikazan.com

ГАМӘЛГӘ КУЮЧЫ (НӘШЕР ИТҮЧЕ) – «ТАТМЕДИА» АҖ
«ТАТМЕДИА» АҖ ФИЛИАЛЫ ҖИТӘКЧЕСЕ –
БАШ МӨХӘРРИР ГӨЛНАРА ИЛЬЯС кызы САБИРОВА.
ЧЫГАРЫЛЫШ ӨЧЕН ҖАВАПЛЫ – РАСИХА ГАБДЕЛБӘР кызы ИСМӘГЫЙЛОВА.
© Газетада басылган язмаларны файдалану, шулай ук өзекләр китерү өчен, «ШК» редакциясеннән язмача рөхсәт алу мәҗбүри. Редакциянең фикере авторларның фикере белән аваздаш булмаска да мөмкин. Редакциянең рәсми оешмаларда юллаучы булып йөрү мөмкинлеге юк. Кульязмалар рецензияләнми һәм кире кайтарылмый. Реклама һәм игъланнардагы мәгълүматларның дөреслеге өчен аны бирүчеләр үзләре җаваплы.
РЕКЛАМА ХЕЗМӘТЕ
Тел: (843) 562-50-12,

ХАТЛАР БҮЛЕГЕ
Тел: (843). 562-50-03,
E-mail: shahri-kazan@tatmedia.com

НӘШРИЯТ
«Татмедиа» АҖ
420097, Казан, Академия ур., 2

16+
Сатудагы бәясе ирекле

Бу санның тиражы – 1545. Гомуми тираж – 5719.
Республика матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр агентлыгы ярдәме белән чыгарыла.
Заказ 675. Газета Элемтә, мәгълүмати технологияләр һәм массакүләм коммуникацияләр өлкәсендә күзәтчелек итү буенча Федераль хезмәттә (Роскомнадзор). 2012 елның 27 августында ПИ №ФС77-50970 нче теркәлү таныклыгы алды. Газета атнага 3 тапкыр – сишәмбе, пәнҗешәмбе һәм җомга көннәрендә чыга. График буенча бу санга 17 сәгатьтә кул куелырга тиеш. Кул куелды – 17 сәгатьтә.

РЕДАКЦИЯ АДРЕСЫ
420066, Казан, Чистай ур., 5 нче йорт
Тел.: (843). 562-50-12, факс: (843). 562-50-07

БАСМАХАНӘ
420066, Казан, Декабристлар ур., 2 нче йорт.
«ТАТМЕДИА» АҖ филиалы «Идел-Пресс» полиграфия-нәшрият комплексы